КУРКЫНЫЧ ҮСЕМЛЕК
Балтырганга каршы ялгыз гына көрәшеп булмый

> 2

АЛЬБЕРТ ХУҖИН:
«Без – мөслимлеләр!» – дип кычкыруларын ишеткәч, сокланган идем»

> 5

ЯРДӘМЧЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ
Татарстандагы 6013 коммерциясез оешма дәүләт ярдәмен тоямы?

> 5

ИСӘНМЕСЕЗ! САЛӒМ ЛӤЙЖЕ!
«Ватаным Татарстан» – мари авылында

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 111 (28884) | Чәршәмбе | 3 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ИСӘНМЕ СЕЗ?!

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ СЪЕЗДЫНДА МИЛЛӘТ КИЛӘЧӘГЕН ФАРАЗЛАДЫЛАР

Мәчет ачсак та, китап нәшер итсәк тә, бәйрәм оештырсак та, нигезебездә милли үзаң булсын. Төрле тарафларга сибелгән татарларны берләштергән Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездының пленар утырышында төп фикер шул булгандыр. Чара конгрессның 30 еллыгына да туры килде. Шулай булгач, башкарган эшләр турында хисап тотылу табигый. Ә киләчәк өчен нишләргә җыеналар? Без кайда һәм без нинди? Татарлар шул сорауларга да җавап эзләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Үткәне – гыйбрәт, киләчәк нинди?

Алдарак язуыбызча, чара конгресс оешуның 30 еллыгына да багышланган иде. Бәйрәм булгач, котлауларны да күпләп кабул иттеләр. Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев әйтмешли, моңа хөрмәт, башкаларның да безнең белән санлашу билгесе итеп карарга кирәк. Россия Президенты Владимир Путинның тәбрикләү сүзләрен дә съездда катнашучыларга ул җиткерде. «Бөтендөнья татар конгрессы Россия төбәкләрендәге, чит илләрдәге милли-мәдәни оешмаларны берләштереп, юбилейны зур уңышлар белән каршы ала. Дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар белән тыгыз хезмәттәшлектә татар халкының туган телен саклап калу өчен эзтәлекле эш алып бара, яшьләрдә традицияләргә тугрылыкны тәрбияли. Бүген татар халкы вәкилләре Ватан каршындагы бурычларын намуслы башкара, Ватанны саклый, хезмәттә, мәдәнияттә, спортта уңыш казана. Дәүләт киләчәктә дә һәр халыкның милли үзенчәлеген саклауга игътибар юнәлтәчәк. Мәдәни, белем бирү үзәкләрен булдыру буенча мәгълүмати проектларга, программаларга ярдәм күрсәтеләчәк. Ышанам: быелгы конгресс Татарстан тормышында якты эз калдырыр, Россия халыклары арасында дуслыкны ныгытыр», – диелгән иде Президент котлавында.

Адәм баласы да 30 яшен тутыргач, артка борылып, башкарган эшләрен барлар иде. Конгресс исә бу дәвердә нәрсәгә ирешкән? Васил Шәйхразыев та шуларны барлады, конгресс оештыруның башлангычында торган кешеләргә рәхмәтен әйтте, арабыздан киткәннәрне искә алды. Әйе, аз эшләнмәгән. Әмма хәзерге көн конгрессның элекке максатлары янына яңа бурыч-сорауларны да өстәми тормый. Кыскасы, якын киләчәктә эш күп. Соңламаска гына иде.

Сан

- Съездга **35** илдән, Россиянең **77** төбәгеннән **1500** кеше җыелды.
- Съездда катнашкан милләттәшләребез: **5** Россия Герое, **105** фән кандидаты, **64** фән докторы, **44** профессор, **7** Олимпия чемпионы.

Кая юл тотабыз?

Утырышта ялкынлы чыгышлар да күп булды. Билгеле, алар «милләтебезнең киләчәге» дип аталучы күчәр тирәсендә әйләнде. «Конгресс алга таба ничек эшләргә тиеш?» дигән сорауга да җавап шәйләнде кайсыларында.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла барыбызны да «Бүген без кем соң?» дигән сорауга җавап эзләргә өндәде.

– Милләт тарихы өчен 30 ел күп вакыт булмаса да, без шушы заман эчендә нинди генә иҗтимагый үзгәрешләр кичермәдек, дәүләт тормышында исә нинди генә әверелешләр күрмәдек! Халкыбыз әйтмешли, кем идек, кем булдык… Ярар, үткән-беткән, бүген без, чыннан да, кем соң? Нинди хәлдә икәнебезне аңлатып тору кирәкмидер, ә менә киләчәгебез нинди? Юлыбыз кая? Тукайның яратып әйтә торган сүзе булган: «Мин әле кая барам?» Без әле кая барабыз? Җавапны без, бәлки, биредә бергәләп эзләрбез, – диде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Ике тапкыр арткан

Быел Россиядә интернеттагы ялган даруханәләр саны ике тапкыр арткан. «Известия» хәбәренә караганда, беренче яртыеллыкта 14 даруханәнең «фальшивка» икәнлеге ачыкланса, хәзер аларның саны 37гә җиткән. Белгечләр әйтүенчә, мошенниклар эзләү системасында (поисковик) үзләренең «аптека»сын реклама аша иң өскә чыгара. Шуңа күрә интернет-даруханә эзләүче кеше иң элек ялганының сайты сылтамасын күреп ала. Ә мондый сайтларда заказ бирүче акчасыз да, товарсыз да калырга мөмкин. Акчасын кулга төшергәч, аферистлар элемтәгә чыгудан туктый чөнки. Шуңа күрә белгечләр ышанычлы, белгән сайтлар аша гына дарулар һәм башка товарларга заказ бирергә киңәш итә.

Мәскәүдән калышмыйбыз

Казан туристларны иң күп җәлеп итүче, алар белән иң әйбәт эшләүче шәһәрләр исемлегенә кергән. Аңа Казаннан тыш, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Сочи эләккән. Кунакчыллык индустриясе берлеге башлыгы Алексей Волков әйтүенчә, Олимпия уеннарын, футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә ирешкән шәһәрләр бу. Шуңа күрә аларда кунакларны кабул итү дә – югары дәрәҗәдә. Әлеге шәһәрләрдәге кунакханәләрдә хезмәт күрсәтүгә зур таләпләр куела. Шул ук вакытта башка калаларның кунакханәләренә квалификацияле хезмәткәрләр җитми.

Сүз уңаеннан, Казанның туризмны үстерү комитеты директоры Дарья Санникова июль азагында белдергәнчә, Татарстан башкаласына туристларның ташкын булып агылуы сәбәпле, экскурсоводлар җитми башлаган. Шуңа күрә якын араларда шәһәрнең истәлекле урыннары турында сөйли белүчеләрдән тагын бер төркем җыю турында игълан ителәчәк.

Иминлек кагыйдәләре тәңгәлләшә

Моннан бер ай чамасы элек Федерация Советында мәктәпләрдә иминлекне тәэмин итү буенча бердәм документ булдырырга тәкъдим ителгән. Документ инде әзерләнеп тә килә икән. Балалар бакчалары һәм мәктәпләрне нәтиҗәлерәк саклау өчен, иминлек кагыйдәләрен тәңгәлләштерү күздә тотыла. Төрле документлардагы каршылыкларны юкка чыгару өчен кирәк бу. Яңа уку елы алдыннан мәктәпләрне Гадәттән тыш хәлләр, Эчке эшләр министрлыклары, Росгвардия, Роспотребнадзор хезмәткәрләре тикшерә. Аларның берише, әйтик, тәрәзәдәге рәшәткәләрне алырга, дисә, икенчесе, киресенчә, ник алдыгыз, дип шелтә белдерергә мөмкин. Алга таба шундый хәлләр килеп чыкмасын өчен, мәгариф оешмалары иминлеген саклау буенча яңа кагыйдәләр әзерләнә. Бу эш август урталарына төгәлләнергә тиеш. Тикшерүчеләр өчен берләштерелгән инструкция нигезендә, мәктәпләрнең иминлеге турында белешмәлек чыгару планлаштырыла.

Алданмаска өйрәтәчәкләр

Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы Россиядә яшәүчеләрне шәхси мәгълүматларын сакларга, мошенниклар корбанына әйләнмәс өчен, интернетта үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтмәкче. Министрлык кайбер оешмалар белән берлектә ил күләмендә кибергигиена программасын башлап җибәргән. Өч еллык программа «Цифрлы икътисад» илкүләм программасының «Мәгълүмат иминлеге» федераль проекты кысасында тормышка ашырыла. «Кибергигиена программасы – тәүге шундый проект. Кешеләргә интернет киңлекләрендә төрле аферистлардан саклану күнекмәләренә өйрәнү мөмкинлеге бирәчәк ул», – ди министрлыкның кибериминлекне тәэмин итү департаменты директоры Владимир Бенгин. Аның әйтүенчә, «пәрәвез» челтәрендә иң күп утыручыларга – балалар һәм үсмерләргә бигрәк тә зур игътибар бирү күздә тотыла.

Программа мәгълүмат иминлеге буенча халыкның аң-белеме үсүгә мониторинг үткәрүне дә үз эченә алачак әле. Тикшеренү нәтиҗәләре кешеләрнең, яшьләре һәм гадәтләренә бәйле рәвештә, интернетта нинди хәтәрләргә ешрак юлыгуларын билгеләү мөмкинлеге бирәчәк. Шуннан чыгып, цифрлы куркынычлардан котылырга өйрәтүче проектлар (шул исәптән күңел ачу рәвешендә) эшләнеләчәк. Программаның аерым бер өлеше дәүләт хезмәткәрләренең мәгълүмат иминлеге буенча аң-белемнәрен үстерүгә багышланачак.

Яңалык

Август үзгәрешләре

Үзмәшгуль булып теркәлү җиңеләя, утлы коралга карата таләпләр катгыйлана, балалар ризыгы рекламасында күкрәк сөте имезүнең файдасы турында да сөйләнәчәк… 1 августтан гамәлгә кергән иң мөһим үзгәрешләрне барладык.

➤ Үзмәшгульләргә рәсми рәвештә теркәлү җиңеләя. Хәзер алар салым органнарына «Минем салым» кушымтасы белән Салым федераль хезмәтенең рәсми сайтындагы шәхси кабинеты аша гына түгел, Дәүләт хезмәтләре порталы аша да исәпкә баса алачак. Салымга бәйле тагын бер яңалык бар. «Һөнәри табышка салым» дигән махсус салым режимыннан хәзер Украина, Донецк һәм Луганск халык республикалары кешеләре дә файдалана алачак.

➤ Наркоманнарны телемедицина ярдәмендә дәвалаячаклар. Бу афәткә бирешкән кешеләргә төгәл диагноз хәзер элеккеге кебек 3–7 көннән соң түгел, 72 сәгать эчендә куелырга тиеш. Наркология диспансерларында оештыру-методик бүлек булдыру да күздә тотыла. Анда мөдир, табиб-статист, медицина статисты белән шәфкать туташы хезмәт куячак.

➤ Утлы корал әйләнеше һәм аны ремонтлау кагыйдәләре катгыйлана. Аның нигезендә, коралны җитештерүче генә түгел, махсус лицензиясе булган юридик затлар да ремонтка тапшыра ала. Юлламаны Росгвардия хезмәтеннән аласы булачак. Сатып алынган ау, сырлы көпшәле утлы спорт коралы, шулай ук шома озын көпшәле утлы коралның гомуми саны (һәр төр буенча) биштән дә артмаска тиеш. Шул ук вакытта бер кешедә исәпләнгән төрле төрдәге кораллар саны уннан да артык булмаска тиеш.

➤ Тикшерү изоляторында да паспорт алып, алмаштырып булачак. Моның өчен гаепләнүче тикшерү изоляторы администрациясенә мөрәҗәгать итәргә тиеш. Алар гаризаны Эчке эшләр министрлыгының җирле территориаль органына җибәрәчәк. Әзер паспортны гариза тапшыруның шәхси эшенә беркетәчәкләр. Билгеле булганча, элегрәк тикшерү изоляторларында мондый хезмәт күрсәтелмәде. Шуның аркасында биредә көн күрүчеләрнең күбесе гаилә кора, инвалидлык ала, гражданлык-хокукый килешүләрдә катнаша алмый иде.

➤ Ротация тәртибендә билгеләнгән дәүләт хезмәткәрләре бу вазыйфада ун елдан да озаграк эшли алмый. Моңа кадәр бу сан биш елны тәшкил итә иде.

➤ Балалар катнашмасы (смесь) рекламасында хәзер күкрәк сөте имезүнең өстенлекләре турында да сөйләнергә тиеш. Моннан тыш әлеге төр продукцияне рекламалаганда яшь чикләве күрсәтелергә, алдан табиб белән киңәшләшергә кирәклеге дә искәртелергә тиеш.

➤ 31 августта Россиядән шикәр, рапс һәм көнбагыш орлыгы чыгаруны вакытлыча чикләү вакыты тәмамлана. Шушы ук көнне Россиядән Евразия Икътисади берлегенә кермәгән илләргә чыгарылган үсемлек мае, көнбагыш орлыгы калдыклары күләмен чикләү срогы да тәмамлана. Бу чикләүләр агымдагы елның март аеннан гамәлдә иде.

Сүзгә-сүз

Александр МАЖУГА, Дәүләт Думасының фән һәм югары белем комитеты рәисе урынбасары:

Әле 10 ел элек кенә чит илләрдән әзер дарулар – таблеткалар, эремәләр сатып алып, банкаларга тутыра һәм аларга этикеткалар ябыштыра идек. Аннан соң таблеткаларны үзебез ясап, блистерларга куярга өйрәндек.

Хәзер яңа дәрәҗәгә күтәрелергә – дару ясау өчен кирәкле матдәләрне Россиянең үзендә булдырырга тиешбез. Шулай итеп, санкцияләр бездә фармацевтика тармагын үстерергә ярдәм итә.

(«Парламентская газета»дан)

БУРЫЧКА АКЧА АЛАСЫЗМЫ?

SuperJob хезмәте белгечләре Россия халкыннан әнә шул хакта сорашкан.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАГДАДТА ТЫНЫЧ ТҮГЕЛ

Планетакүләм вазгыять киеренке булып калуын дәвам итә. Дөрес, әлегә зур конфликтларның оеткысы гына саклана һәм алар, бәхеткә, стакан эчендәге давылны хәтерләтә. Әмма теләсә кайсы мизгелдә вазгыять контрольдән чыгарга мөмкин.

Соңгы тәүлектә атом-төш коралы турында берничә рәсми белдерү ясалды. БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш: «Кешелек җәмгыяте атом-төш һәлакәтеннән бер ялгышу ераклыгында гына тора», – дип белдерде. Дубайдан кайтып төшкәч, Россиянең элекке Президенты Медведев та: «Хәзер вазгыять салкын сугышка караганда күпкә начаррак!» – дигән сүзләр әйтте. Бу кадәресен, әлбәттә, барыбыз да беләбез. Путинның да атом сугышына бәйле игъланы яңгырады. «Атом сугышында җиңүчеләр була алмый һәм ул беркайчан да башланырга тиеш түгел», – диде Кремль лидеры. Мәскәү тарафыннан вазгыятьне шулай аңлау сөендерә, билгеле. Вашингтон да темага үз өлешен өстәде. АКШның Дәүләт секретаре Блинкен: «АКШ атом арсеналын куллану мөмкинлеген экстремаль вазгыятьтә генә карый ала», – диде. Экстремаль вазгыятьнең һәр сәгать саен туып торуын искә алсак, Блинкен сүзләре борчулы тудыра.

Бу юллар иkenче август иртәсендә языла. Кичкә Нэнси Пелосиның Тайбэйдагы Суншань аэропортына очкыч белән төшеп утыруы мәгълүм булды. Grand Hyatt отелендә төн кунганнан соң, 3 август иртәсендә утрау җитәкчелеге белән очрашырга ниятли. Пекинның визитка кискен хәрби җавап бирергә вәгъдә итүен искә алганда, хәл бик катлаулы. Төбәктә бик зур көчләр капма-каршы тора. Әмма газета хәбәрчесе фаразлый: искитәрлек берни дә булмас, мөгаен. Бәрелеш «тел сугышы» дәрәҗәсеннән узып китмәс. Атна ахырына, бәлки, без Кытай – Тайвань – Америка каршылыгының эчке пружиналарын тасвирларга язма әзерләрбез. Әлегә давыл җимерүләрсез генә узып китәр дип уйлыйбыз. Имилекне бер кеше дә гарантияли алмый, әлбәттә, чөнки кеше факторы дигән нәрсә бар. Бер ялгыш хәрәкәт зур бәрелешкә китерергә мөмкин.

Җир шарына төшкән фетнә очкыны бу юлы Багдадта ярыйсы гына зур янгын чыгарды. Гыйракта шигый төркемнәре үзара бәрелешә. Хакимлек өчен көрәш каты бара. «Координацион структура» дип аталган төркем илнең премьер-министрына үз кандидатураларын тәкъдим иткән иде. Мона риза булмыйча, дини һәм сәяси лидер Мөктада ас-Садра тарафдарлары 30 июль көнне иртән «Яшел зона»ны штурм белән алдылар һәм парламентка бәреп керделәр. Багдадка хәрби техника кертелде, әмма баш күтәрүчеләр халык бернигә карамый, ас-садрачыларны яклап, шәһәр үзәгенә таба юнәлә. Югары түрәләрнең бик күбесе илне ташлап качты, ә хәрби разведка башлыгы баш күтәрүчеләр ягына күчте, дигән хәбәрләр алынды.

Джо Байден Әфганстанда америкалыларның Әл-Кыаида* башлыгы Айман әз-Завәһирины утерүләре хакында рәсми белдерү ясады. Бу янкиларның зур җиңүе итеп тәкъдим ителде.

* Россиядә тыелган террорчыл оешма

Россиядә

МИЛЛИАРДЕРЛАР БӨЛӘ, ВАЛЮТА ДЕПОЗИТЛАРЫ ЯНА

Россиянең Үзәк банкы өметле белдерү ясады: өченче квартал нәтиҗәләре буенча икътисад түнтәрелеше 7 процент булачак. Икенче кварталда түбәнәю 4,3 процент булган. Икътисад ныграк егылыр дип көткәннәр иде, вазгыятьнең оптимизмы менә шунда.

Әйе, әйе, авыр хәлдәге тармаклар бик күп. Металлурглар, мәсәлән, җитештерелгән продукцияне кая куярга белми, чөнки Көнбатыш базарларына үтеп керү мөмкин түгел диярлек. Икенче кварталда экспорт 20 процентка кимегән. Эчке базарда да металл куллану кими, бәяләр төшә. Дөнья икътисады акрынаю сәбәпле, экспортка саткан металл да аз табыш китерә, чөнки аларда да бу төр чималга хакны аз түлиләр. Россия Президенты Владимир Путин тармак проблемаларына кагылышлы махсус киңәшмә үткәрде, эчке базарда ихтыяҗны арттырырга чакырды.

Экспортның табышсыз булуының тагын бер сәбәбе бар: финанс хакимиятләре сумны күпме генә йомшартырга тырышмасын, теләгән нәтиҗәгә ирешә алмыйлар. Доллар һәм евро курсының түбән булуы кайчандыр кыйммәтле валютаны депозитка салган халыкны гасабиландыра. Россия банклары депозитта валюта саклаган өчен тискәре процентлар кертергә тырыша, чит илгә акча күчергәндә дә шактый зур комиссияләр алалар. Җитмәсә, валюта курслары доллар-евро ияләре өчен зур югалтулар китерә торган. Белгечләр доллар һәм евро Россиянең эчке базарында 30 процент кыйммәтен югалттылар дип бәяли. Кайчан гына әле рәсми финанс хакимиятләре дә россиялеләргә акчаларын сумнарда, долларларда һәм евроларда сакларга киңәш итә иде. Хәзер бу киңәш искерде, актуальлеген югалтты. Бердән, Көнбатыштагы югары инфляция ике резерв валютасының да сатып алу көчен юкка чыгара. Икенчедән, доллар-евро курслары рубльгә карата бик түбәнәйде. Шуларга өстәп, Үзәк банк банк хисапларындагы валютаны алуга чикләүләрне киләсе елның мартына кадәр озайтты. Халык кулында 85 миллиард доллар кәгазь валюта бар дип фаразлана, депозитларда 90 миллиард доллар акрын гына сыза-яна, диләр. Депозиттагы валюта кертемнәре өчен процентлар түләнми, аны саклаган өчен депозит ияләреннән комиссия түләтү белән яныйлар.

Хәзер банклардагы валюта кертеме ияләре бер генә нәрсәгә өметләнә: хөкүмәт йомшартуга йөз токкач, сум доллар-евро каршында көчсезләнми калмас, диләр. Долларны 70–80 сумга җиткерү планы бар бит. Әмма әлегә сум ул планга бик буйсынып ук бетми. Сум инфляциясенең зур булуы да, төп ставканы түбәнәйтү дә тиз генә нәтиҗә бирми. Импортны арттыру сумны йомшартыр дигән өмет бар, тик анысы да әле тиз генә тормышка ашардай түгел кебек.

Россияле миллиардерларга да җиңел түгел. 2022 ел башыннан олигархлар 60 миллиард доллар акча югалтты. Россияле миллиардерлар клубында исемлек шактый зур, бүлгәч югалтулар, бәлки, түзәрлектер. Әмма байларга бер тиен югалту да катастрофа булып тоела, анысы да бар.

ИСӘНМЕ СЕЗ?!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ркаил Зәйдулла милли мәгарифнең әһәмияте турында искә төшерде.

– Халкыбызның инде яртысыннан күбрәге татарча белми, белгәннәренең дә теле ярым-йорты гына. Чөнки безнең милли мәгарифебез юк кимәлендә, милли мәктәпләр челтәре тар-мар ителде. Инкыйразның шәүләсе мәктәпләрдә, урамнарда, эш кабинетларында гына түгел, ә өйләрдә, түр башында киерелеп утыра. Туган телләр рәтенә урыс телен кертеп, аны ата-аналарга ирекле сайлау хокукы биреп, бик мәкерле эшләделәр, хәзер күп баланың ата-анасы гына түгел, әби-бабасы да татарча белми. Алар туган тел дигәндә нинди телне сайласын?! – диде ул.

Ркаил Зәйдулла әйтмешли, бер генә халыкның да тарих сәхнәсеннән төшеп каласы килми. Татарның да яшәү көче бар, билгеле. Югалмас өчен нишлисе соң?

– Быелтыр миңа Оренбург Каргалысында булырга туры килгән иде. Анда алар милли тәрбия бирә торган балалар үзәге ачкан. Шундый ук үзәкләр Чувашиянең зур татар авылларында, Пенза өлкәсенең атаклы Урта Әләзән авылында да бар. Хосусый мәктәпләр ачарга менә дигән җирлек! Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен, ата-аналарын да җәлеп итеп, якшәмбе мәктәпләре челтәрен барлыкка китерү дә максатка ярашлы булыр иде, – дигән фикердә язучы. Шулай ук мәчетләрне, үткәндә калган тәҗрибә буенча, хосусый мәктәпләр, мәдрәсәләр белән ныгытырга кирәк, диде ул.

«Милләт Җыены»нда ук кискен һәм туры сүзләре белән истә калган Казахстан татарлары һәм башкортлары конгрессы рәисе урынбасары, «Туран» университеты профессоры Гриф Хәйруллин бу юлы да уйландырды.

– Кайбер кимчелекләргә игътибар итәргә дә кирәк. Беренчедән, без тарихта эзлебез, дип шапырынырга яратабыз. Ә гөрләтеп татарча укытырлык мәктәпләр җәелдердекме? Татарча университет ачтыкмы? Юк бит! Сувенир халык булу өчен генә тырышмыйбызмы, шул юлдан бармыйбызмы икән? – дип чыгыш ясады ул. – Икенчедән, безнең татар яшьләре башка милләт вәкилләре белән гаилә коруны хуп күрә. Анысы да ярар иде. Әмма бу гаиләдә туган балалар татар булмый. Без шуны уйлыйбызмы? Без җиңәрлек киртәләр күп, әлбәттә. Шуларны җиңәр өчен терәк кирәк. Без – читтәге татарлар – шул терәк итеп Татарстанны күрәбез. Эшләребез бара, ал да гөл сыман. Шулай да нидер җитми кебек. Уйлана торгач, шундый фикергә килдем. Без татарча сөйләшсәк, биесәк, җырласак, «без – татар» дип кычкырсак, шул җитә дип уйлыйбыз. Ләкин эшебезнең тышы гына бу. Нигезебездә милли үзаң булырга тиеш. Эшебез тышкы күренеш белән генә чикләнәме? Шуны уйласак иде.

Берләшү бәһасе

Утырышта Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә чыгыш ясады. Аксакал үткәнебезне искә төшерде, конгресс оешкан елларга тукталды. Шунысы берәүне дә шикләндерми: 1992 елдагы тәүге съезд барлык ышанычларны да аклады.

– 30 ел элек без, татарлар, үз тарихыбызда беренче тапкыр, бөтен дөньядан тарихи Ватаныбызга җыелдык. Без ул чакта очраштык-күрештек, татарның милләт буларак исәнлегенә ышандык. Ул чакта безгә конгрессның җыелуы һәм рухи бердәмлегебезне раслау бик мөһим иде. Беренче корылтай, Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитетын оештырып, үз бурычын үтәде. Аның беренче җитәкчесе Индус Ризак улы Таһиров безнең өметләрне аклады дип саныйм. Халкыбыз тарихын барыбыздан да яхшырак белә торган күренекле галим, үзенең милләт каршында җаваплылыгын тоеп эшләде. Беренче корылтайда мин конгрессны: «Җир шарында көн күрүче татарларны берләштерүче, барлык татарлар исеменнән рәсми сүз әйтә алучы олы һәм вәкаләтле мәҗлес», – дип белдергән идем. Ул мәлдә барлык делегатлар моны алкышлап хуплады. Шуннан соң бер шигебез дә калмады: үзебезнең тарихи дөрес эшкә тотынуыбызга инандык, – диде Дәүләт Киңәшчесе.

Бергә эшләдек, сездә терәк, таяныч таптык, моннан соң да шулай булыр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, делегатларны сәламләп, аларга рәхмәтләрен җиткерде.

– Ватанпәрвәр булуыгыз, динебез, телебез, гореф-гадәтләрне саклауда күрсәткән хезмәтегез өчен рәхмәт. Без булдырабыз! Бергә булырга насыйп булсын. Биредә күп фикерләр яңгырады. Тәнкыйть тә булды. Әлбәттә, кабул итәбез. Без үз эшебездән канәгать түгел. Эшебез күп. Безнең эшләр яхшы, дип кенә ярамый. Глобальләшү чорында үзебезне ничек саклап калу турында уйларга кирәк, – диде Татарстан Президенты. – Гаилә, дин мөһим. Мәчет намаз уку урыны гына түгел, ул тел өйрәнү үзәге дә булырга тиеш. Безнең алда торган барлык бурычларны бергә хәл итә алуыбызга шик юк. Безнең көч – бердәмлектә!

Кунаклар кәефе

Читтән фикер тансык. Чарага килгән кунакларның да фикерен белештек. Алар Казанга нинди өметләр белән килгән дә нинди хисләр белән китә икән?

1999–2010 елларда Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле булып торган Мәскәү кунагы Назыйф Мириханов милли мәгариф турында уйланыр чак дигән фикердә.

– 30 еллык дәверне алсак, эшләгән эшләребез күп. Конгресс җитәкчесе бу хакта әйтте. Нигез бар, көч бар. Хәзерге көндә калкып торган төп мәсьәлә – милли мәгарифнең юкка чыгуы. Игътибарны әнә шуңа юнәлтсәк, яхшырак булыр иде. Безнең эшебезнең шактый өлешен, Латин Америкасы халыклары сыман, күңел ачу биләп ала. Моны үзебез дә сизмәстән шулай итәбез, – ди ул. – Мәгариф реформасы бармады түгел, барды. Без аны үзебез дә кулдан ычкындырдык. Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам: татар телен атнага ике тапкыр укытып кына саклап булмый! Мәҗбүри укыргамы, ирекләме дип тә карыйлар. Әмма ике сәгатькә калгач... Оныкларым шәһәрдә яши. Быел җәй алар белән юньләп татарча сөйләшә алмадым. Аңламыйлар бит. Теле булмаган халыкның мәдәнияте дә, эстрадасы да булмый. Ничек кенә булса да, мәгариф системасына татар мәктәпләрен кайтару юнәлешендә эшләргә кирәк. Бүгенге вазгыять һәм кануннар кысаларында әле эшләргә була. Алдагы биш елда шулар турында уйланырга кирәк.

Ханты-Манси автономияле округыннан Рәзидә Гарифуллина Казаннан матур хис-кичерешләр генә алып китә. Съездда беренче катнашуы, ә Татарстан башкаласына беренче генә килми икән инде. Балалары да татарларның мәркәзендә көн күрә.

– Казанга килүемә сөенеп туя алмыйм. Ханты-Мансиның Когалым шәһәрендә «Гаилә кыйммәтләре» дигән түгәрәк алып барам. Әти-әниләр, әбиләр, балалар белән эшлим. Милләт, тел, мәдәният саклансын өчен, гореф-гадәтләрне яңартырга тырышабыз, шул юнәлештә эш алып барабыз. Яшьләребез дә өметле, – дип сөйләде Рәзидә Гарифуллина. – Читтә яшәсәк тә, гаиләдә татар телле мохит булды. Өч баламда Казан тирәсенә күченеп кайтты. Әле менә съезд кысасында Болгарга барып кайттык. «Әнием, мин гел татарча гына сөйләшәчәкмен. Ирем дә, туачак балаларым да татар телен беләчәк!» – диде кызым. Бу сүзләрне ишетүемә бик сөендем. Казаннан бик күп рухи байлык алып кайтам!

Башкортстан делегациясе вәкиле, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Фән Вәлиәхмәтов съездга беренче тапкыр гына килми.

– Хисләрне әйтеп аңлата торган түгел. Күңел күтәренке, кәеф яхшы. Башкортстаннан делегация иң зуры, – ди Фән ага. – Өмет шул: яшь буын милли моңны, телне онытмасын иде. Русча кушып сөйләшкән балаларда милли аһәң була алмый. Телне бәләкәйдән – бишектән өйрәтергә, үзаңны кечкенәдән күтәрергә кирәк. Моның өчен милли мәгариф булса яхшы.

...Съезд узды. Кунаклар да канәгать калгандыр. Әмма бар нәрсәдән канәгать булу да гел яхшы түгел. Камиллеккә чикләр юк. Өметләр ишетелде, алар аклансын өчен биш ел җитәрме?! Вакыт күрсәтер.

Утырыш кысасында делегатлар Васил Шәйхразыевны кабат Милли Шура рәисе итеп сайлады һәм оешманың яңа составын раслады. Анда 75 вәкил керде.

«Кызу» август

Җәйнең соңгы ае төрле дәрәҗәдәге чара, фестиваль, концерт, күргәзмәләргә бай булачак. Аларның күбесе, мәдәният бинасы кысалары белән генә чикләнмичә, ачык һавада узачак. Аларны республика халкы гына түгел, Татарстанга кунакка килгән туристлар да тамаша кыла алачак.

Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова сүзләренә караганда, август «кызу» булачак. Кичә генә Казанда «Тормыш стиле – мәдәни код» дип исемләнгән II Халык иҗаты һәм гамәли-декоратив сәнгать фестивале башланып китте. «Хәзинә» галереясында бу көннәрдә Россиядә яшәүче халыкларның традицияләрен, мәдәни мирасын яктырткан күргәзмә белән танышырга мөмкин. Казан Кремлендә 7 августка кадәр эшләячәк Россия халыкларының этник музыка фестивале, мода күргәзмәсе дә республика халкында зур кызыксыну уятыр дип өметләнә оештыручылар. Соңгысында Россиянең 24 төбәге һәм БДБнең 6 иле дизайнерларының эшләре тәкъдим ителгән. Гомумән, август дәвамында Казан Кремлендә бик күп күргәзмәләр белән танышырга мөмкин булачак.

Август аен тулыландырачак мәдәни чараларның иң зурысы Болгарда узачак. 13–14 август көннәрендә биредә «Бөек Болгар» урта гасыр көрәше илкүләм фестивале узачак. Быел ул Идел Болгарында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышлана. Шушы фестиваль кысасында беренче тапкыр ачык һавада «Кара пулат» операсы күрсәтеләчәк. Шул рәвешле композитор Эльмир Низамовның Ренат Харис либреттосы буенча язылган «Кара пулат» операсы янәдән тамашачы хозурына – бу юлы инде үзгә шартларда тәкъдим ителәчәк.

– Әлеге опера 2015 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге «Яңарыш» фонды ярдәмендә Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында куелган иде. 2022 елның май аенда К.Тинчурин театрында кабаттан күрсәтелде, – дип ачыклык кертте Ирада Әюпова журналистлар белән очрашуда.

30 августта башкаланың Камал театры каршына, елдагыча, республиканың иң оста гармунчылары җыелачак. Биредә «Уйнагыз, гармуннар!» фестивале узачак. Атна саен чәршәмбе көнне Казанда «Габдулла Тукай һәм татар театры тарихы» дип аталган яңа экскурсион маршрут эшли. Ул җәйнең соңгы аенда да үз эшен дәвам итәчәк. Аның кысасында 10–15 кешелек бер төркем татар халкының бөек шагыйрен бөтенләй башка яктан ачкан яңа маршрут буенча йөреп чыга. Экскурсия барышында Тукай әдәби музеенда беренче татар артистларының шәхси ядкәрләре белән танышу, Иске Татар бистәсендә Тукай һәм театр тарихы эзләрен барлау, Шәрык клубына сәяхәт, Г.Камал театрының түбәсеннән Казанның тарихи урыннарына күзәтү ясау каралган.

7 август көнне Зөя утрау-шәһәрчегендә узачак «Том Сойер» фестивалендә катнашучылар бу тамашаны күзәтеп кенә калмыйча, аңа үз өлешен дә кертеп, 1969 елда төзелгән тарихи бинаны буярга ярдәм итә ала. Алабуга музей-тыюлыгының да август аена планнары зурдан. 5–7 август көннәрендә биредә XVII тапкыр Спас ярминкәсе фестивале узачак. Алда телгә алган барлык чараларны да, республика халкы белән беррәттән, туристлар да тамаша кыла алачак.

Татарстанның туризм буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Гөлнара Сафина сүзләренә караганда, бер ел эчендә республиканың төп туризм үзәкләренә агылган туристлар саны бермә-бер арткан. Татарстанда туристлар, нигездә, дүрт-биш көнгә туктала. 29 апрельдә Мәскәү белән Санкт-Петербургтан Казанга туристик чартерлар ачылган. «Идел буенда якты яллар» төбәкара проекты кысасында 30 апрельдән Идел буеның биш төбәге аша Ижау – Казан – Самара – Тольятти – Казан – Ижау маршруты буенча туристик поезд йөри башлады. Татарстанга килгән туристлар саны, нигездә, әнә шулар хисабына артты, ди белгечләр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БАЛТЫРГАНГА КАРШЫ... КӨРӘК БЕЛӘН

Яшәеш

Җиләк сезонында кая гына барса да, җиләкченең машинасында чиләк булыр, дип шаярталар. Балтач районы Яңгул авыл җирлеге башлыгы Ранил Габдрахманов машинасында исә җәй буе көрәк йөри, ди. Юллар начар булганга яки машина батып калган очраклар өчен түгел, анда-монда берән-сәрән үскән балтырганнарны (борщевикларны) чабар өчен кирәк аңа көрәк.

Мин яшәгән авылларда балтырган әллә ни күренмәсә дә, Куныр, Түнтәр, Урта Көшкәт, Субаш, Шеңшеңәр, Чутай, Иске Көшкәт, Чепья авыллары ягында күп алар. Шөкер, җир гел эшкәртелеп тору сәбәпле, басу-кырларда юк, диләр. Бездән сигез чакрымда гына булган Яңгул җирлегенә караган авылларда алар шактый үрчеп өлгергән шул.

– Бу арада гына мәйданын үлчәгән юк, биш гектарга якын дип йөри идем, белмим, арткандыр да инде, – ди Ранил, бу турыда сорашкач. – Бигрәк тә Иске Көшкәт ягында күп. Ул яктагысын «Яңа тормыш» хуҗалыгы техникасы ярдәмендә эшкәрттек, тамырыннан ук кузгаттык. Борнакка чыгу юлында исә авыл җирлеге, мәдәният йорты, китапханә хезмәткәрләре белән өмә ясап, иртә язда ук чаптык. Кызганыч, алар инде бүген кабат күтәрелеп килә. Хуҗалык җитәкчесе белән яңадан нәкъ шулай ук эшкәртү турында сөйләштек. Дәвамлы булмаса, нәтиҗә көтеп булмаячак. Шунысы да борчый: ул инде гомер уйламаган урыннарда да күренә башлады. Әйтик, быелга кадәр авылыбызның Тырыш ягы елгаларында юк иде, быел инде очрый. Машинада көрәк йөри инде, сирәк очраганнарын чабып китәбез...

«Ватсап»тагы авыл төркемнәрендә Куныр, Көшкәтбаш авылларында да балтырганга каршы өмәләр үткәрүләре турында хәбәрләр күренә. Ни генә булса да, бу юнәлештә эшләнгән һәр гамәл, һәр чара мөһим. Битарафлык гафу ителми.

– Балтырган белән дөрес көрәшмиләр, – ди, бу хакта сүз чыккач, бер таныш агроном. – Мин аның турында бик күп укыдым, өйрәндем. Ул бит – икееллык кына үлән, орлыгын җыеп алсаң, киләсе елга тишелмәячәк.

– Өч метр биеклеккә кадәр үсә бит ул. Орлыгын ничек җыярга кирәк? Өстәвенә агулы үлән. Янына килә торган түгел, – дим. – Согы гына түгел, серкәсе, исе һәм хәтта чыгы да куркыныч. Тән генә түгел, үпкәләр өчен дә бик хәтәр, диләр...

– Мин дә орлыгын бөртекләп җыярга димим бит, – ди ул, үз фикерендә калып. – Үләнне яшь вакытта түгел, нәкъ менә орлыгы өлгерер алдыннан чабарга кирәк.

– Белмим инде, интернетта, тамырыннан ук казып алсаң гына котылып була, дигәннәр. Бернәрсәгә дә бирешми: салкыннардан, хәтта радиациядән дә курыкмый. Авыруларга чыдам, корткычлар яратмый. Бер үсемлек 100 меңгә кадәр орлык бирә, алар җирдә 15 елга кадәр «йокларга» һәм шуннан соң үсәргә мөмкин, дип язганнар бит, – дип, мин дә үзем белгәннәр белән каршы киләм. – Тузганакны шау чәчәктә чакта чабып атсаң да, орлыгын чәчеп өлгерә. Бу да шуның кебектер инде, болай җиңел генә котылып булса, галим-белгечләр шул юлны тәкъдим итәрләр иде. Һәр елны үсеп китәргә ирек бирмичә чабып торсаң, кимендә биш елдан аларның мәйданы кими башлаячак, диләр бит.

Ул – үз фикерендә, мин үз фикеремдә калдык. Балтырганга каршы ялгыз гына көрәшеп булмый, ил күләмендәге дәүләт программасы кирәк, диючеләр дөрес әйтәдер кебек тоела миңа. 2020 елда бу уңайдан «боз кузгалган» иде инде, тендерлар отып, махсус оешмалар эш башларга да тиеш иде. Әмма пандемия үз төзәтмәләрен кертте. Хәер, пандемия сәбәп кенә булды, дисәк тә дөрес булыр. Тендерны бездә, мәсәлән, ниндидер Казанныкылар откан, авыл җирлекләреннән, өмә ясатып, эшләргә (бушка!) кешеләр эзләп йөргәннәр дигәннәр иде. Бу проблеманың уңай хәл ителүе шул җирлектә яшәүчеләр өчен бик мөһим, читләрне ахыргы нәтиҗәдән бигрәк акча өлеше генә кызыксындыра. Бу гомергә шулай булды. Соңгы вакытта авыл җирлекләренең үзләренә бюджеттан махсус шушы юнәлешкә беркадәр акча бүлеп бирелә башлаган. Безнең Балтач районында, мәсәлән, бу проблема булган ун авыл җирлегенә ике миллион 334 мең сум акча бүлеп бирелгән. «Барлык урыннарда да бу уңайдан нәрсәдер эшләнде, – ди Ранил. – Кайбер авыллар химикатлар белән дә эшкәртте, бездә балтырган уңайсыз урыннарда үсә, андый мөмкинлек булмады...»

«ВТ» архивыннан

Безнең илдә балтырган Бөек Ватан сугышыннан соң барлыкка килә. Халык аны «Сталин үләне» дип йөрткән, чөнки илдә таралуының төп гаеплесе ул чактагы ил башлыгы Сталин була. Кайчандыр культуралы үсемлек булып, бүген иң хәтәр чүп үлән саналган балтырганга каршы соңгы елларда гына ил күләмендә көрәш алып барыла башлады. Ул бары тик 2012 елда гына «хуҗалыкта файдасын югалткан» дип танылa һәм селекционерлар казанышларының дәүләт реестрыннан төшерелә. 2015 елда Россиянең чүп үләннәр тармак классификаторына кертелә (ягъни чүп үлән булып санала), ә 2019 башлап елдан аны үрчеткән өчен штрафлар салына башлый. Россия буенча әлеге үлән 40 миллион гектарны биләп алган, аның мәйданы ел саен 10 процентка артып бара.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын аулау лимитын раслау турында

«Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Аучылык ресурсларын аулау лимитын килештерү турында» 2022 елның 20 июнендәге 05-29-29/22882 номерлы хатын һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 31 маендагы 415-п номерлы боерыгын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. 2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын аулау лимитын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Указның 1 пункты белән расланган аучылык ресурсларын аулау лимиты чикләрендә һәр аучылык биләмәсе өчен аучылык ресурсларын аулау квоталарын 2–9 нчы кушымталар нигезендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә Указның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә, шулай ук аның күчермәсен Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгына билгеләнгән вакытларда тапшырырга.

4. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремель. 2022 ел, 30 июль
№ ПУ-517

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә 2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга аучылык ресурсларын аулау лимиты

Т/с	Аучылык ресурслары төре	Баш саны	Аулау лимиты: баш саны	Аулау лимиты: гомуми саннан %
1	Поши	13 635	683	5,01
2	Себер кыр кәҗәсе	12 708	521	4,10
3	Затлы нәселле болан	142	0	0,00
4	Селәүсен	81	4	4,94
5	Бурсык	3 247	197	6,07

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
2 нче кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасында беркетелгән аучылык биләмәләре (аучылык хуҗалыклары) территориясендә аучылык ресурсларын (поши) аулау квоталары

Т/с	Беркетелгән аучылык биләмәсе атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квотасы, баш саны
1	2	3	4	5	6
1	«7 завод»	25,4	55	2,17	3
2	«Азнакай»	55,6	7	0,13	0
3	«Ак Барс»	69,1	202	2,92	14
4	«Аксубай»	48,6	100	2,06	7
5	«Актаныш»	139,4	542	3,89	35
6	«Албай»	16,9	116	6,86	11
7	«Апас»	96,8	57	0,59	1
8	«Арча»	24,5	0	0,00	0
9	«Әтнә»	63,5	117	1,84	5
10	«Баганино»	87,9	136	1,55	5
11	«Багражъ»	40,4	224	5,54	15
12	«Баек урманы»	-	-	-	-
13	«Бакчасарай»	19,1	65	3,40	4
14	«Барс»	34,3	46	1,34	2
15	«Бөркет»	40,7	235	5,77	18
16	«Берсут»	8,7	36	4,14	2
17	«Олы Карагуҗа»	19,8	53	2,68	3
18	«Бөгелмә»	97,7	177	1,81	8
19	«Буа»	138,0	102	0,74	3
20	«Бута-Чишмә»	88,4	156	1,76	7
21	«Вепрь»	-	-	-	-
22	«Югары Ослан»	64,1	155	2,42	10
23	«Идел»	9,8	51	5,20	4
24	«Идел-Кама»	19,1	69	3,61	4
25	«Нократ яры»	42,5	329	7,74	16
26	«Нократ»	-	-	-	-
27	«Глухарь»	45,5	234	5,14	8
28	«Дубрава»	-	-	-	-
29	«Егерь»	-	-	-	-
30	«Алабуга»	26,6	30	1,13	1
31	«Елхов урманы»	29,4	128	4,35	10
32	«Забава»	1,3	37	28,88	2
33	«Зәй»	37,4	148	3,96	10
34	«Зеленодольск»	26,6	126	4,74	10
35	«Зүзәй»	32,1	127	3,96	7
36	«Кайбыч»	39,3	121	3,08	8
37	«Кама-Исмәгыйль»	28,3	59	2,08	4
38	«Кама яры»	8,9	17	1,91	0
39	«Кама-Ык»	17,1	62	3,63	4
40	«Кама киңлекләре»	14,0	58	4,14	4
41	«Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана)	16,2	33	2,04	2
42	«Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы файдалана)	22,2	55	2,48	3
43	«Караеш»	25,6	88	3,44	6
44	«Карамалы»	22,1	242	10,95	25
45	«Кызыл Юл»	20,5	64	3,12	4
46	«Зариф Кордоны»	40,7	115	2,83	8
47	«Красный Бор»	71,2	432	6,07	30
48	«Красновидово»	35,8	151	4,22	12
49	«Кызыл Октябрь»	9,5	74	7,79	7
50	«Куйбышев»	72,0	71	0,99	2
51	«Кукмара»	12,7	7	0,55	0
52	«Ласка»	50,1	94	1,88	4
53	«Лебяжье» (Минзәлә районы)	24,4	90	3,69	6
54	«Лебяжье» (Чирмешән районы)	17,9	107	5,98	8
55	«Лубян»	11,4	29	2,54	2
56	«Марал»	-	-	-	-
57	«Минзәлә»	97,9	310	3,17	21
58	«Алексеевск районының аучылар һәм балыкчылар җирле иҗтимагый оешмасы»	48,8	111	2,27	3
59	«Мизин»	8,1	0	0,00	0
60	«Мөслим»	9,9	64	6,46	6
61	«Никольский»	15,6	27	1,73	1
62	«Яңа Минзәлә»	28,2	63	2,23	4
63	«Нурма»	31,1	50	1,61	2
64	«Омара»	50,1	83	1,66	4
65	«Аучы»	19,5	61	3,13	4
66	«Аучылык традицияләре»	24,7	109	4,41	8
67	«Аучылык традицияләре 2»	20,3	17	0,84	0
68	«Питрәч»	50,7	89	1,76	4
69	«Поповское»	20,0	54	2,70	3
70	«Салават күпере»	21,7	151	6,96	10
71	«Селәүсен»	138,6	282	2,03	18
72	«Сарман»	48,8	71	1,45	3
73	«Свиногорье»	54,6	144	2,64	10
74	«Зөя»	46,8	138	2,95	1
75	«Төньяк»	40,6	84	2,07	4
76	«Сухарево»	36,1	160	4,43	12
77	«Тархан»	10,5	65	6,19	6
78	«Тәмте» (Югары Ослан районы)	22,0	72	3,27	2
79	«Тәмте» (Кама Тамагы районы)	45,5	48	1,05	2
80	«Тәтеш»	77,9	131	1,68	6
81	«Трофей»	21,4	78	3,64	4
82	«Төрнәс»	23,2	187	8,06	17
83	«Урахча»	8,1	84	10,37	6
84	«Урман»	27,7	74	2,67	5
85	«Үрнәк»	35,2	194	5,51	15
86	«Усы»	8,1	79	9,75	9
87	«Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы»	298,8	1016	3,40	25
88	«Фазан»	16,3	5	0,31	0
89	«Форест»	-	-	-	-
90	«Чаллы»	40,4	121	3,00	5
91	«Чирмешән»	53,0	98	1,85	4
92	«Ширәмәт»	41,8	131	3,13	9
93	«Чишмә»	56,4	165	2,93	11
94	«Шуман»	16,0	0	0,00	0
95	«Көньяк»	19,6	217	11,07	20
96	«Юкә»	13,4	35	2,61	2
97	«Ямаш»	12,1	109	9,01	13
98	«Янтык»	43,3	159	3,67	11
	БАРЛЫГЫ				654

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
3 нче кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасында ачык аучылык биләмәләре һәм төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары территорияләрендә аучылык ресурсларын (поши) аулау квоталары

Т/с	Муниципаль районнарның ачык аучылык биләмәләре һәм аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган башка территория атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квоталары: барлыгы, баш саны	шул исәптән: 1 яшьтән өлкән, баш саны: куышу чорында ата пошилар	шул исәптән: 1 яшьтән өлкән, баш саны: җенесенә карамастан	шул исәптән: 1 яшькә кадәр, баш саны
1	2	3	4	5	6	7	8	9
	Ачык аучылык биләмәләре							
1	Әгерҗе районы	51,6	118	2,29	4	0	3	1
1	Әгерҗе районы	51,6	118	2,29	4	0	3	1
2	Азнакай районы	145,4	234	1,61	1	0	0	1
3	Аксубай районы	38,8	32	0,82	0	0	0	0
4	Алексеевск районы	96,2	74	0,77	1	0	0	1
5	Әлки районы	148,5	131	0,88	2	0	1	1
6	Әлмәт районы	44,1	119	2,70	4	0	3	1
7	Арча районы	39,3	7	0,18	0	0	0	0
8	Баулы районы	93,8	51	0,54	1	0	0	1
9	Балтач районы	57,3	19	0,33	0	0	0	0
10	Бөгелмә районы	14,8	7	0,47	0	0	0	0
11	Биектау районы	21,0	4	0,19	0	0	0	0
12	Чүпрәле районы	83,9	7	0,08	0	0	0	0
13	Алабуга районы	21,6	7	0,32	0	0	0	0
14	Зеленодольск районы	-	-	-	-	-	-	-
15	Кайбыч районы	19,4	3	0,15	0	0	0	0
16	Лаеш районы	-	-	-	-	-	-	-
17	Лениногорск районы	29,7	123	4,14	5	0	4	1
18	Мамадыш районы	44,0	23	0,52	0	0	0	0
19	Менделеевск районы	61,5	42	0,68	0	0	0	0
20	Мөслим районы	47,0	11	0,23	0	0	0	0
21	Түбән Кама районы	18,0	51	2,83	2	0	1	1
22	Яңа Чишмә районы	77,1	173	2,24	0	0	0	0
23	Нурлат районы	165,1	102	0,62	1	0	0	1
24	Балык Бистәсе районы	83,0	272	3,28	4	0	3	1
25	Сарман районы	92,1	68	0,74	1	0	0	1
26	Спас районы	100,1	28	0,28	0	0	0	0
27	Тәтеш районы	39,6	4	0,10	0	0	0	0
28	Тукай районы	72,8	18	0,25	0	0	0	0
29	Чирмешән районы	57,1	18	0,32	0	0	0	0
30	Чистай районы	97,1	22	0,23	0	0	0	0
31	Ютазы районы	71,2	101	1,42	3	0	2	1
	Төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары							
32	«Әгерҗе»	30,9	120	3,88	0	0	0	0
33	«Биләр»	12,9	75	5,81	0	0	0	0
34	«Урман Чишмәсе»	23,7	75	3,16	0	0	0	0
35	«Мишә»	131,7	477	3,62	0	0	0	0
36	«Сурнар»	13,5	54	4,00	0	0	0	0
	БАРЛЫГЫ				29	0	17	12

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
4 нче кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасында беркетелгән аучылык биләмәләре (аучылык хуҗалыклары) территорияләрендә аучылык ресурсларын (себер кыр кәҗәсе) аулау квоталары

Т/с	Беркетелгән аучылык биләмәсе атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квотасы, баш саны
1	2	3	4	5	6
1	«7 завод»	25,4	229	9,02	12
2	«Азнакай»	55,6	271	4,87	15
3	«Ак Барс»	69,1	297	4,30	12
4	«Аксубай»	48,6	46	0,95	1
5	«Актаныш»	139,4	489	3,51	30
6	«Албай»	16,9	0	0,00	0
7	«Апас»	96,8	60	0,62	1
8	«Арча»	24,5	0	0,00	0
9	«Әтнә»	63,5	0	0,00	0
10	«Баганино»	87,9	149	1,70	5
11	«Багражъ»	40,4	129	3,19	5
12	«Баек урманы»	7,6	44	5,79	3
13	«Бакчасарай»	19,1	57	2,98	3
14	«Барс»	34,3	39	1,14	1
15	«Бөркет»	40,7	200	4,91	16
16	«Берсут»	8,7	0	0,00	0
17	«Олы Карагуҗа»	19,8	0	0,00	0
18	«Бөгелмә»	97,7	258	2,64	18
19	«Буа»	138,0	129	0,93	3
20	«Бута-Чишмә»	88,4	93	1,05	4
21	«Вепрь»	-	-	-	-
22	«Югары Ослан»	64,1	206	3,21	0
23	«Идел»	9,8	25	2,55	0
24	«Идел-Кама»	19,1	62	3,25	4
25	«Нократ яры»	42,5	175	4,12	14
26	«Нократ»	-	-	-	-
27	«Глухарь»	45,5	0	0,00	0
28	«Дубрава»	3,5	55	15,71	5
29	«Егерь»	-	-	-	-
30	«Алабуга»	26,6	32	1,20	0
31	«Елхов урманы»	29,4	178	6,05	15
32	«Забава»	1,3	0	0,00	0
33	«Зәй»	37,4	233	6,23	15
34	«Зеленодольск»	26,6	0	0,00	0
35	«Зүзәй»	32,1	146	4,55	7
36	«Кайбыч»	39,3	62	1,58	3
37	«Кама-Исмәгыйль»	28,3	126	4,45	10
38	«Кама яры»	8,9	4	0,45	0
39	«Кама-Ык»	17,1	36	2,11	0
40	«Кама киңлекләре»	14,0	53	3,79	3
41	«Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана)	16,2	8	0,49	0
42	«Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы файдалана)	22,2	124	5,59	2
43	«Караеш»	25,6	86	3,36	6
44	«Карамалы»	22,1	161	7,29	15
45	«Кызыл Юл»	20,5	55	2,68	3
46	«Зариф Кордоны»	40,7	0	0,00	0
47	«Красный Бор»	71,2	28	0,39	0
48	«Красновидово»	35,8	165	4,61	12
49	«Кызыл Октябрь»	9,5	0	0,00	0
50	«Куйбышев»	72,0	229	3,18	16
51	«Кукмара»	12,7	1	0,08	0
52	«Ласка»	50,1	241	4,81	9
53	«Лебяжье» (Минзәлә районы)	24,4	53	2,17	0
54	«Лебяжье» (Чирмешән районы)	17,9	112	6,26	11
55	«Лубян»	11,4	0	0,00	0
56	«Марал»	-	-	-	-
57	«Минзәлә»	97,9	121	1,24	6
58	«Алексеевск районының аучылар һәм балыкчылар җирле иҗтимагый оешмасы»	48,8	298	6,11	10
59	«Мизин»	8,1	0	0,00	0
60	«Мөслим»	9,9	67	6,77	6
61	«Никольский»	15,6	87	5,58	3
62	«Яңа Минзәлә»	28,2	105	3,72	7
63	«Нурма»	31,1	34	1,09	1
64	«Омара»	50,1	40	0,80	1
65	«Аучы»	19,5	42	2,15	2
66	«Аучылык традицияләре»	24,7	0	0,00	0
67	«Аучылык традицияләре 2»	20,3	0	0,00	0
68	«Питрәч»	50,7	28	0,55	0
69	«Поповское»	20,0	104	5,20	8
70	«Салават күпере»	21,7	25	1,15	0
71	«Селәүсен»	138,6	398	2,87	20
72	«Сарман»	48,8	93	1,91	4
73	«Свиногорье»	54,6	192	3,52	13
74	«Зөя»	46,8	132	2,82	0
75	«Төньяк»	40,6	0	0,00	0
76	«Сухарево»	36,1	205	5,68	12
77	«Тархан»	10,5	94	8,95	6
78	«Тәмте» (Югары Ослан районы)	22,0	83	3,77	2
79	«Тәмте» (Кама Тамагы районы)	45,5	120	2,64	3
80	«Тәтеш»	77,9	80	1,03	4
81	«Трофей»	21,4	0	0,00	0
82	«Төрнәс»	23,2	279	12,03	12
83	«Урахча»	8,1	12	1,48	0
84	«Урман»	27,7	85	3,07	0
85	«Үрнәк»	35,2	0	0,00	0
86	«Усы»	8,1	115	14,20	21
87	«Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы»	298,8	0	0,00	0
88	«Фазан»	16,3	36	2,21	2
89	«Форест»	-	-	-	-
90	«Чаллы»	40,4	178	4,41	5
91	«Чирмешән»	53,0	119	2,25	8
92	«Ширәмәт»	41,8	105	2,51	7
93	«Чишмә»	56,4	96	1,70	4
94	«Шуман»	16,0	0	0,00	0
95	«Көньяк»	19,6	228	11,63	20
96	«Юкә»	13,4	72	5,37	5
97	«Ямаш»	12,1	43	3,55	3
98	«Янтык»	43,3	11	0,25	0
	БАРЛЫГЫ				474

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
5 нче кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасында ачык аучылык биләмәләре һәм төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары территорияләрендә аучылык ресурсларын (себер кыр кәҗәсе) аулау квоталары

Т/с	Муниципаль районнарның ачык аучылык биләмәләре һәм аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган башка территория атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квоталары: барлыгы, баш саны	шул исәптән: 1 яшьтән өлкән, баш саны: куышу чорында кәҗә тәкәләре	шул исәптән: 1 яшьтән өлкән, баш саны: җенесенә карамастан	шул исәптән: 1 яшькә кадәр, баш саны
1	2	3	4	5	6	7	8	9
	Ачык аучылык биләмәләре							
1	Әгерҗе районы	51,6	24	0,47	0	0	0	0
2	Азнакай районы	145,4	709	4,88	2	0	1	1
3	Аксубай районы	38,8	56	1,44	1	0	0	1
4	Алексеевск районы	96,2	309	3,21	5	0	3	2
5	Әлки районы	148,5	353	2,38	5	0	3	2
6	Әлмәт районы	44,1	103	2,34	2	0	1	1
7	Арча районы	39,3	0	0,00	0	0	0	0
8	Баулы районы	93,8	400	4,26	8	0	5	3
9	Балтач районы	57,3	0	0,00	0	0	0	0
10	Бөгелмә районы	14,8	96	6,49	4	0	2	2
11	Биектау районы	21,0	0	0,00	0	0	0	0
12	Чүпрәле районы	83,9	76	0,91	0	0	0	0
13	Алабуга районы	21,6	20	0,93	0	0	0	0
14	Зеленодольск районы	-	-	-	-	-	-	-
15	Кайбыч районы	19,4	8	0,41	0	0	0	0
16	Лаеш районы	-	-	-	-	-	-	-
17	Лениногорск районы	29,7	198	6,67	5	0	3	2
18	Мамадыш районы	44,0	0	0,00	0	0	0	0
19	Менделеевск районы	61,5	0	0,00	0	0	0	0
20	Мөслим районы	47,0	21	0,45	0	0	0	0
21	Түбән Кама районы	18,0	214	11,89	3	0	2	1
22	Яңа Чишмә районы	77,1	422	5,47	2	0	1	1
23	Нурлат районы	165,1	197	1,19	3	0	2	1
24	Балык Бистәсе районы	83,0	0	0,00	0	0	0	0
25	Сарман районы	92,1	163	1,77	2	0	1	1
26	Спас районы	100,1	108	1,08	2	0	1	1
27	Тәтеш районы	39,6	29	0,73	0	0	0	0
28	Тукай районы	72,8	31	0,43	0	0	0	0
29	Чирмешән районы	57,1	33	0,58	0	0	0	0
30	Чистай районы	97,1	55	0,57	0	0	0	0
31	Ютазы районы	71,2	107	1,50	3	0	2	1
	Төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары							
32	«Әгерҗе»	30,9	0	0,00	0	0	0	0
33	«Биләр»	12,9	44	3,41	0	0	0	0
34	«Урман Чишмәсе»	23,7	59	2,49	0	0	0	0
35	«Мишә»	131,7	0	0,00	0	0	0	0
36	«Сурнар»	13,5	0	0,00	0	0	0	0
	БАРЛЫГЫ				47	0	27	20

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
6 нчы кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасында беркетелгән аучылык биләмәләре (аучылык хуҗалыклары) территориясендә аучылык ресурсларын (затлы нәселле болан) аулау квоталары

Т/с	Беркетелгән аучылык биләмәсе атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квоталары, баш саны
1	2	3	4	5	6
1	«7 завод»	25,4	0	0,00	0
2	«Азнакай»	55,6	0	0,00	0
3	«Ак Барс»	69,1	0	0,00	0
4	«Аксубай»	48,6	0	0,00	0
5	«Актаныш»	139,4	0	0,00	0
6	«Албай»	16,9	0	0,00	0
7	«Апас»	96,8	0	0,00	0
8	«Арча»	24,5	0	0,00	0
9	«Әтнә»	63,5	0	0,00	0
10	«Баганино»	87,9	0	0,00	0
11	«Багражъ»	40,4	0	0,00	0
12	«Баек урманы»	-	-	-	-
13	«Бакчасарай»	19,1	0	0,00	0
14	«Барс»	34,3	0	0,00	0
15	«Бөркет»	40,7	0	0,00	0
16	«Берсут»	8,7	0	0,00	0
17	«Олы Карагуҗа»	19,8	0	0,00	0
18	«Бөгелмә»	97,7	0	0,00	0
19	«Буа»	138,0	0	0,00	0
20	«Бута-Чишмә»	88,4	0	0,00	0
21	«Вепрь»	-	-	-	-
22	«Югары Ослан»	64,1	0	0,00	0
23	«Идел»	9,8	0	0,00	0
24	«Идел-Кама»	19,1	0	0,00	0
25	«Нократ яры»	42,5	0	0,00	0
26	«Нократ»	-	-	-	-
27	«Глухарь»	45,5	0	0,00	0
28	«Дубрава»	-	-	-	-
29	«Егерь»	-	-	-	-
30	«Алабуга»	26,6	0	0,00	0
31	«Елхов урманы»	29,4	0	0,00	0
32	«Забава»	-	-	-	-
33	«Зәй»	37,4	0	0,00	0
34	«Зеленодольск»	26,6	0	0,00	0
35	«Зүзәй»	32,1	0	0,00	0
36	«Кайбыч»	39,3	0	0,00	0
37	«Кама-Исмәгыйль»	28,3	0	0,00	0
38	«Кама яры»	8,9	0	0,00	0
39	«Кама-Ык»	17,1	0	0,00	0
40	«Кама киңлекләре»	14,0	0	0,00	0
41	«Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана)	16,2	0	0,00	0
42	«Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы файдалана)	22,2	0	0,00	0
43	«Караеш»	25,6	0	0,00	0
44	«Карамалы»	22,1	0	0,00	0
45	«Кызыл Юл»	20,5	0	0,00	0
46	«Зариф Кордоны»	40,7	0	0,00	0
47	«Красный Бор»	71,2	0	0,00	0
48	«Красновидово»	35,8	0	0,00	0
49	«Кызыл Октябрь»	9,5	0	0,00	0
50	«Куйбышев»	72,0	0	0,00	0
51	«Кукмара»	12,7	0	0,00	0
52	«Ласка»	50,1	0	0,00	0
53	«Лебяжье» (Минзәлә районы)	24,4	0	0,00	0
54	«Лебяжье» (Чирмешән районы)	17,9	0	0,00	0
55	«Лубян»	11,4	0	0,00	0
56	«Марал»	-	-	-	-
57	«Минзәлә»	97,9	0	0,00	0
58	«Алексеевск районының аучылар һәм балыкчылар җирле иҗтимагый оешмасы»	48,8	0	0,00	0
59	«Мизин»	8,1	0	0,00	0
60	«Мөслим»	9,9	0	0,00	0
61	«Никольский»	15,6	0	0,00	0
62	«Яңа Минзәлә»	28,2	0	0,00	0
63	«Нурма»	31,1	0	0,00	0
64	«Омара»	50,1	0	0,00	0
65	«Аучы»	19,5	0	0,00	0
66	«Аучылык традицияләре»	24,7	0	0,00	0
67	«Аучылык традицияләре 2»	20,3	0	0,00	0
68	«Питрәч»	50,7	0	0,00	0
69	«Поповское»	20,0	0	0,00	0
70	«Салават күпере»	21,7	0	0,00	0
71	«Селәүсен»	138,6	0	0,00	0
72	«Сарман»	48,8	0	0,00	0
73	«Свиногорье»	54,6	0	0,00	0
74	«Зөя»	46,8	0	0,00	0
75	«Төньяк»	40,6	0	0,00	0
76	«Сухарево»	36,1	0	0,00	0
77	«Тархан»	10,5	0	0,00	0
78	«Тәмте» (Югары Ослан районы)	22,0	0	0,00	0

Ахыры 4 нче биттә >

1	2	3	4	5	6
79	«Тәмте» (Кама Тамагы районы)	45,5	0	0,00	0
80	«Тәтеш»	77,9	0	0,00	0
81	«Трофей»	21,4	0	0,00	0
82	«Төрнәс»	23,2	0	0,00	0
83	«Урахча»	8,1	0	0,00	0
84	«Урман»	27,7	0	0,00	0
85	«Үрнәк»	35,2	0	0,00	0
86	«Усы»	8,1	0	0,00	0
87	«Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы»	298,8	87	0,29	0
88	«Фазан»	16,3	0	0,00	0
89	«Форест»	-	-	-	-
90	«Чаллы»	40,4	0	0,00	0
91	«Чирмешән»	53,0	0	0,00	0
92	«Ширәмәт»	41,8	0	0,00	0
93	«Чишмә»	56,4	0	0,00	0
94	«Шуман»	16,0	0	0,00	0
95	«Көньяк»	19,6	1	0,05	0
96	«Юкә»	13,4	0	0,00	0
97	«Ямаш»	12,1	0	0,00	0
98	«Янтык»	43,3	0	0,00	0
БАРЛЫГЫ					0

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
7 нче кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасында ачык аучылык биләмәләре һәм төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары территорияләрендә аучылык ресурсларын (затлы нәселле болан) аулау квоталары

Т/с	Муниципаль районнарның ачык аучылык биләмәләре һәм аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган башка территория атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квоталары			
					барлыгы, баш саны	шул исәптән		
						1 яшьтән өлкән, баш саны		1 яшькә кадәр, баш саны
						куышу чорында ата боланнар	женесенә карамастан	
1	2	3	4	5	6	7	8	9
Ачык аучылык биләмәләре								
1	Әгерҗе районы	51,6	0	0,00	0	0	0	0
2	Азнакай районы	145,4	0	0,00	0	0	0	0
3	Аксубай районы	38,8	0	0,00	0	0	0	0
4	Алексеевск районы	96,2	0	0,00	0	0	0	0
5	Әлки районы	148,5	0	0,00	0	0	0	0
6	Әлмәт районы	44,1	0	0,00	0	0	0	0
7	Арча районы	39,3	0	0,00	0	0	0	0
8	Баулы районы	93,8	0	0,00	0	0	0	0
9	Балтач районы	57,3	0	0,00	0	0	0	0
10	Бөгелмә районы	14,8	0	0,00	0	0	0	0
11	Биектау районы	21,0	0	0,00	0	0	0	0
12	Чүпрәле районы	83,9	0	0,00	0	0	0	0
13	Алабуга районы	21,6	0	0,00	0	0	0	0
14	Зеленодольск районы	-	-	-	-	-	-	-
15	Кайбыч районы	19,4	0	0,00	0	0	0	0
16	Лаеш районы	-	-	-	-	-	-	-
17	Лениногорск районы	29,7	0	0,00	0	0	0	0
18	Мамадыш районы	44,0	0	0,00	0	0	0	0
19	Менделеевск районы	61,5	0	0,00	0	0	0	0
20	Мөслим районы	47,0	0	0,00	0	0	0	0
21	Түбән Кама районы	18,0	0	0,00	0	0	0	0
22	Яңа Чишмә районы	77,1	0	0,00	0	0	0	0
23	Нурлат районы	165,1	0	0,00	0	0	0	0
24	Балык Бистәсе районы	83,0	0	0,00	0	0	0	0
25	Сарман районы	92,1	0	0,00	0	0	0	0
26	Спас районы	100,1	0	0,00	0	0	0	0
27	Тәтеш районы	39,6	0	0,00	0	0	0	0
28	Тукай районы	72,8	0	0,00	0	0	0	0
29	Чирмешән районы	57,1	0	0,00	0	0	0	0
30	Чистай районы	97,1	0	0,00	0	0	0	0
31	Ютазы районы	71,2	0	0,00	0	0	0	0
Төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары								
32	«Әгерҗе»	30,9	0	0,00	0	0	0	0
33	«Биләр»	12,9	0	0,00	0	0	0	0
34	«Урман Чишмәсе»	23,7	54	2,28	0	0	0	0
35	«Мишә»	131,7	0	0,00	0	0	0	0
36	«Сурнар»	13,5	0	0,00	0	0	0	0
БАРЛЫГЫ					0	0	0	0

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
8 нче кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорда Татарстан Республикасында аучылык ресурсларын (селәүсен) аулау квоталары

Т/с	Муниципаль районнарның ачык аучылык биләмәләре һәм аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган башка территория атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квоталары, баш саны
1	2	3	4	5	6
Беркетелгән аучылык биләмәләре (аучылык хуҗалыклары)					
1	«7 завод»	25,4	0	0,00	0
2	«Азнакай»	55,6	10	0,18	1
3	«Ак Барс»	69,1	0	0,00	0
4	«Аксубай»	48,6	0	0,00	0
5	«Актаныш»	139,4	0	0,00	0
6	«Албай»	16,9	0	0,00	0
7	«Апас»	96,8	0	0,00	0
8	«Арча»	24,5	0	0,00	0
9	«Әтнә»	63,5	0	0,00	0
10	«Баганино»	87,9	0	0,00	0
11	«Баграж»	40,4	0	0,00	0
12	«Баек урманы»	-	-	-	-
13	«Бакчасарай»	19,1	0	0,00	0
14	«Барс»	34,3	0	0,00	0
15	«Бөркет»	40,7	0	0,00	0
16	«Берсут»	8,7	0	0,00	0
17	«Олы Карагуҗа»	19,8	0	0,00	0
18	«Бөгелмә»	97,7	7	0,07	0
19	«Буа»	138,0	0	0,00	0
20	«Бута-Чишмә»	88,4	2	0,02	0
21	«Вепрь»	-	-	-	-
22	«Югары Ослан»	64,1	0	0,00	0
23	«Идел»	9,8	0	0,00	0
24	«Идел-Кама»	19,1	0	0,00	0
25	«Нократ яры»	42,5	0	0,00	0
26	«Нократ»	-	-	-	-
27	«Глухарь»	45,5	0	0,00	0
28	«Дубрава»	-	-	-	-
29	«Егерь»	-	-	-	-
30	«Алабуга»	26,6	0	0,00	0
31	«Елхов урманы»	29,4	0	0,00	0
32	«Забава»	-	-	-	-
33	«Зәй»	37,4	0	0,00	0
34	«Зеленодольск»	26,6	0	0,00	0
35	«Зүзәй»	32,1	2	0,06	0
36	«Кайбыч»	39,3	0	0,00	0
37	«Кама-Исмәгыйль»	28,3	3	0,11	0
38	«Кама яры»	8,9	0	0,00	0
39	«Кама-Ык»	17,1	0	0,00	0
40	«Кама киңлекләре»	14,0	0	0,00	0
41	«Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана)	16,2	0	0,00	0
42	«Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы файдалана)	22,2	0	0,00	0
43	«Караеш»	25,6	0	0,00	0
44	«Карамалы»	22,1	0	0,00	0
45	«Кызыл Юл»	20,5	0	0,00	0
46	«Зариф Кордоны»	40,7	0	0,00	0
47	«Красный Бор»	71,2	31	0,44	3
48	«Красновидово»	35,8	0	0,00	0
49	«Кызыл Октябрь»	9,5	0	0,00	0
50	«Куйбышев»	72,0	0	0,00	0
51	«Кукмара»	12,7	0	0,00	0
52	«Ласка»	50,1	0	0,00	0
53	«Лебяжье» (Минзәлә районы)	24,4	0	0,00	0
54	«Лебяжье» (Чирмешән районы)	17,9	0	0,00	0
55	«Лубян»	11,4	0	0,00	0
56	«Марал»	-	-	-	-
57	«Минзәлә»	97,9	0	0,00	0
58	«Алексеевск районының аучылар һәм балыкчылар җирле иҗтимагый оешмасы»	48,8	0	0,00	0
59	«Мизин»	8,1	0	0,00	0
60	«Мөслим»	9,9	0	0,00	0
61	«Никольский»	15,6	0	0,00	0
62	«Яңа Минзәлә»	28,2	0	0,00	0
63	«Нурма»	31,1	1	0,03	0
64	«Омара»	50,1	0	0,00	0
65	«Аучы»	19,5	0	0,00	0
66	«Аучылык традицияләре»	24,7	0	0,00	0
67	«Аучылык традицияләре 2»	20,3	0	0,00	0
68	«Питрәч»	50,7	0	0,00	0
69	«Поповское»	20,0	0	0,00	0
70	«Салават күпере»	21,7	0	0,00	0
71	«Селәүсен»	138,6	0	0,00	0
72	«Сарман»	48,8	0	0,00	0
73	«Свиногорье»	54,6	0	0,00	0
74	«Зөя»	46,8	0	0,00	0
75	«Төньяк»	40,6	0	0,00	0
76	«Сухарево»	36,1	0	0,00	0
77	«Тархан»	10,5	0	0,00	0
78	«Тәмте» (Югары Ослан районы)	22,0	0	0,00	0
79	«Тәмте» (Кама Тамагы районы)	45,5	0	0,00	0
80	«Тәтеш»	77,9	0	0,00	0
81	«Трофей»	21,4	0	0,00	0
82	«Төрнәс»	23,2	0	0,00	0
83	«Урахча»	8,1	0	0,00	0
84	«Урман»	27,7	1	0,04	0
85	«Үрнәк»	35,2	0	0,00	0
86	«Усы»	8,1	0	0,00	0
87	«Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы»	298,8	7	0,02	0
88	«Фазан»	16,3	0	0,00	0
89	«Форест»	-	-	-	-
90	«Чаллы»	40,4	0	0,00	0
91	«Чирмешән»	53,0	0	0,00	0
92	«Ширәмәт»	41,8	0	0,00	0
93	«Чишмә»	56,4	0	0,00	0
94	«Шуман»	16,0	0	0,00	0
95	«Көньяк»	19,6	0	0,00	0
96	«Юкә»	13,4	1	0,07	0
97	«Ямаш»	12,1	3	0,25	0
98	«Янтык»	43,3	0	0,00	0
Ачык аучылык биләмәләре					
99	Әгерҗе	51,6	3	0,06	0
100	Азнакай	145,4	1	0,01	0
101	Аксубай	38,8	0	0,00	0
102	Алексеевск	96,2	0	0,00	0
103	Әлки	148,5	0	0,00	0
104	Әлмәт	44,1	0	0,00	0
105	Арча	39,3	2	0,05	0
106	Баулы	93,8	0	0,00	0
107	Балтач	57,3	3	0,05	0
108	Бөгелмә	14,8	0	0,00	0
109	Биектау	21,0	0	0,00	0
110	Чүпрәле	83,9	0	0,00	0
111	Алабуга	21,6	0	0,00	0
112	Зеленодольск	-	-	-	-
113	Кайбыч	19,4	0	0,00	0
114	Лаеш	-	-	-	-
115	Лениногорск	29,7	1	0,03	0
116	Мамадыш	44,0	0	0,00	0
117	Менделеевск	61,5	0	0,00	0
118	Мөслим	47,0	0	0,00	0
119	Түбән Кама	18,0	0	0,00	0
120	Яңа Чишмә	77,1	0	0,00	0
121	Нурлат	165,1	0	0,00	0
122	Балык Бистәсе	83,0	1	0,01	0
123	Сарман	92,1	0	0,00	0
124	Спас	100,1	0	0,00	0
125	Тәтеш	39,6	0	0,00	0
126	Тукай	72,8	0	0,00	0
127	Чирмешән	57,1	0	0,00	0
128	Чистай	97,1	0	0,00	0
129	Ютазы	71,2	0	0,00	0
Төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары					
130	«Әгерҗе»	30,9	1	0,03	0
131	«Биләр»	12,9	0	0,00	0
132	«Урман Чишмәсе»	23,7	0	0,00	0
133	«Мишә»	131,7	1	0,01	0
134	«Сурнар»	13,5	0	0,00	0
БАРЛЫГЫ					4

Татарстан Республикасы Президентының
2022 елның 30 июлендәге ПУ-517 номерлы Указына
9 нчы кушымта

2022 елның 1 августыннан 2023 елның 1 августына кадәрге чорда Татарстан Республикасында аучылык ресурсларын (бурсык) аулау квоталары

Т/с	Муниципаль районнарның ачык аучылык биләмәләре һәм аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган башка территория атамасы	Аучылык ресурслары төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданы, мең га	Аучылык ресурслары төренең баш саны	Аучылык ресурсларының урнашу тыгызлыгы, аучылык ресурсларының әлеге төренең баш саны билгеләнгән яшәү тирәлеге категорияләре мәйданының 1000 гектарына баш саны	Аулау квоталары, баш саны
1	2	3	4	5	6
Беркетелгән аучылык биләмәләре (аучылык хуҗалыклары)					
1	«7 завод»	25,4	25	0,98	2
2	«Азнакай»	55,6	69	1,24	6
3	«Ак Барс»	69,1	91	1,32	9
4	«Аксубай»	48,6	65	1,34	2
5	«Актаныш»	139,4	89	0,64	8
6	«Албай»	16,9	9	0,53	0
7	«Апас»	96,8	8	0,08	0
8	«Арча»	24,5	0	0,00	0
9	«Әтнә»	63,5	0	0,00	0
10	«Баганино»	87,9	33	0,38	3
11	«Баграж»	40,4	46	1,14	2
12	«Баек урманы»	7,6	0	0,00	0
13	«Бакчасарай»	-	-	-	-
14	«Барс»	34,3	10	0,29	0
15	«Бөркет»	40,7	65	1,60	6
16	«Берсут»	8,7	5	0,57	0
17	«Олы Карагуҗа»	19,8	0	0,00	0
18	«Бөгелмә»	97,7	42	0,43	4
19	«Буа»	138,0	30	0,22	3
20	«Бута-Чишмә»	88,4	48	0,54	0
21	«Вепрь»	1,1	0	0,00	0
22	«Югары Ослан»	64,1	59	0,92	0
23	«Идел»	9,8	12	1,22	1
24	«Идел-Кама»	19,1	16	0,84	1
25	«Нократ яры»	42,5	35	0,82	3
26	«Нократ»	0,8	13	16,25	1
27	«Глухарь»	45,5	13	0,29	1
28	«Дубрава»	3,5	4	1,14	0
29	«Егерь»	2,3	0	0,00	0
30	«Алабуга»	26,6	21	0,79	2
31	«Елхов урманы»	29,4	45	1,53	4
32	«Забава»	5,6	32	5,71	2
33	«Зәй»	37,4	59	1,58	4
34	«Зеленодольск»	26,6	7	0,26	0
35	«Зүзәй»	32,1	19	0,59	0
36	«Кайбыч»	39,3	9	0,23	0
37	«Кама-Исмәгыйль»	28,3	45	1,59	4
38	«Кама яры»	8,9	9	1,01	0
39	«Кама-Ык»	17,1	42	2,46	4
40	«Кама киңлекләре»	14,0	0	0,00	0
41	«Кама Тамагы» («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте файдалана)	16,2	41	2,53	0
42	«Кама Тамагы» («Кама Тамагы аучылык хуҗалыгы» җирле иҗтимагый оешмасы файдалана)	22,2	28	1,26	2
43	«Караеш»	25,6	0	0,00	0
44	«Карамалы»	22,1	32	1,45	2
45	«Кызыл Юл»	20,5	37	1,80	2
46	«Зариф Кордоны»	40,7	9	0,22	0
47	«Красный Бор»	71,2	108	1,52	10
48	«Красновидово»	35,8	23	0,64	2
49	«Кызыл Октябрь»	9,5	0	0,00	0
50	«Куйбышев»	72,0	43	0,60	4
51	«Кукмара»	12,7	18	1,42	1
52	«Ласка»	50,1	57	1,14	3
53	«Лебяжье» (Минзәлә районы)	24,4	39	1,60	3
54	«Лебяжье» (Чирмешән районы)	17,9	29	1,62	2
55	«Лубян»	11,4	0	0,00	0
56	«Марал»	0,6	0	0,00	0
57	«Минзәлә»	97,9	72	0,74	7
58	«Алексеевск районының аучылар һәм балыкчылар җирле иҗтимагый оешмасы»	48,8	66	1,35	5
59	«Мизин»	8,1	1	0,12	0
60	«Мөслим»	9,9	60	6,06	6
61	«Никольский»	15,6	8	0,51	0
62	«Яңа Минзәлә»	28,2	44	1,56	4
63	«Норма»	31,1	12	0,39	1
64	«Омара»	50,1	30	0,60	0
65	«Аучы»	19,5	41	2,10	2
66	«Аучылык традицияләре»	24,7	0	0,00	0
67	«Аучылык традицияләре 2»	20,3	0	0,00	0
68	«Питрәч»	50,7	26	0,51	2
69	«Поповское»	20,0	21	1,05	2
70	«Салават күпере»	21,7	22	1,01	2
71	«Селәүсен»	138,6	52	0,38	5
72	«Сарман»	48,8	56	1,15	5
73	«Свиногорье»	54,6	25	0,46	2
74	«Зөя»	46,8	26	0,56	0
75	«Төньяк»	40,6	16	0,39	1
76	«Сухарево»	36,1	22	0,61	2
77	«Тархан»	10,5	0	0,00	0
78	«Тәмте» (Югары Ослан районы)	-	-	-	-
79	«Тәмте» (Кама Тамагы районы)	45,5	25	0,55	0
80	«Тәтеш»	77,9	22	0,28	2
81	«Трофей»	21,4	0	0,00	0
82	«Төрнәс»	23,2	36	1,55	3
83	«Урахча»	8,1	20	2,47	2
84	«Урман»	27,7	21	0,76	0
85	«Үрнәк»	35,2	48	1,36	4
86	«Усы»	8,1	36	4,44	3
87	«Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы»	298,8	50	0,17	5
88	«Фазан»	16,3	18	1,10	1
89	«Форест»	-	-	-	-
90	«Чаллы»	40,4	19	0,47	0
91	«Чирмешән»	53,0	40	0,75	4
92	«Ширәмәт»	41,8	10	0,24	0
93	«Чишмә»	56,4	10	0,18	1
94	«Шуман»	16,0	7	0,44	0
95	«Көньяк»	19,6	0	0,00	0
96	«Юкә»	13,4	25	1,87	2
97	«Ямаш»	12,1	42	3,47	3
98	«Янтык»	43,3	0	0,00	0
Ачык аучылык биләмәләре					
99	Әгерҗе районы	51,6	56	1,09	3
100	Азнакай районы	145,4	51	0,35	3
101	Аксубай районы	38,8	1	0,03	0
102	Алексеевск районы	96,2	37	0,38	0
103	Әлки районы	148,5	17	0,11	1
104	Әлмәт районы	44,1	27	0,61	1
105	Арча районы	39,3	5	0,13	0
106	Баулы районы	93,8	80	0,85	2
107	Балтач районы	57,3	16	0,28	0
108	Бөгелмә районы	14,8	15	1,01	0
109	Биектау районы	21,0	0	0,00	0
110	Чүпрәле районы	83,9	0	0,00	0
111	Алабуга районы	21,6	7	0,32	0
112	Зеленодольск районы	5,0	0	0,00	0
113	Кайбыч районы	19,4	6	0,31	0
114	Лаеш районы	5,7	0	0,00	0
115	Лениногорск районы	29,7	46	1,55	2
116	Мамадыш районы	44,0	4	0,09	0
117	Менделеевск районы	61,5	13	0,21	1
118	Мөслим районы	47,0	22	0,47	0
119	Түбән Кама районы	18,0	13	0,72	0
120	Яңа Чишмә районы	77,1	31	0,40	1
121	Нурлат районы	165,1	12	0,07	0
122	Балык Бистәсе районы	83,0	18	0,22	0
123	Сарман районы	92,1	40	0,43	2
124	Спас районы	100,1	17	0,17	0
125	Тәтеш районы	39,6	0	0,00	0
126	Тукай районы	72,8	0	0,00	0
127	Чирмешән районы	57,1	21	0,37	0
128	Чистай районы	97,1	18	0,19	1
129	Ютазы районы	71,2	28	0,39	1
Төбәк әһәмиятенә ия дәүләт табигать зоология (аучылык) заказниклары					
130	«Әгерҗе»	30,9	18	0,58	0
131	«Биләр»	12,9	9	0,70	0
132	«Урман Чишмәсе»	23,7	14	0,59	0
133	«Мишә»	131,7	23	0,17	0
134	«Сурнар»	13,5	14	1,04	0
БАРЛЫГЫ					197

ПЕСИДӘ ДӘ... ТАЛПАН

Авыл сулышы

Мәгълүмат чаралары быел яздан бирле талпаннардан зыян күрүче кешеләрнең алдагы еллардагыдан күпкә артык булуы турында чаң кага. Урманга, табигатькә баручыларга саклык чаралары күрү турында да күп кисәтәләр. Баксаң, талпан (халык телендә – урман бете) эзләп, урманга барып йөрисе дә юк, ул үзе, безне эзләп, авылга, ишегалдына килә икән.

Күптән түгел апамның Казаннан кайткан оныгы җәй башында гына туган бер песи баласын күтәреп килгән. «Моның ияк астында нәрсәдер бар. Урман бете түгелме ул?» – ди.

– Нинди урман бете булсын, каян килсен, миң үскәндер, – дип, бармак белән суккалап, селкетеп тә күрсәттем әле. Энекәшем аны абыйсына да күрсәткән булып чыкты. Ул да: «Урман бете бит инде», – дигәч, тиз генә интернетны эшкә җиктек. Ничек алып була, янәсе. Әй, җаным, анда язып та күрсәткәннәр! Миннән генә була торган эш түгел бу, дим.

Сан

Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе хәбәр итүенчә, быел талпан кадалудан зарланып, белгечләргә 7069 кеше мөрәҗәгать иткән. Бу – гадәти күрсәткечләрдән 1,3 тапкыр күбрәк. Мондый очракларның күбесе Казан (1461), Чаллыда (1320) һәм Әлмәт районында (742) теркәлгән. Апас районында исә бер очрак та булмаган.

Рәхмәт төшкере, күрше Фәйрүзәнең бер елны: «Көтүдән сыерга урман бете кадалып кайткан иде», – дигәне искә төште.

Интернетта өйрәткәнчә, пинцетны спирт белән эшкәртеп, спиртлы мамык тотып, песи баласын кыстырып, күршеләргә кереп киттем. Олы кызлары Зөһрә, урман бете түгелме икән дигәнне ишетүгә: «Безнең Ләйсән ала аны», – дип кереп китте. Ләйсәннәре бүген Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында ветеринария табиблыгына укый. Мал-туарны, кош-кортны бала чактан ярата. Дөрестән дә, урман бете алганы бар икән.

– Әле күптән түгел генә тау башында бозауны урман бете сарып алган иде бит, – ди Фәйрүзә. – Ләйсән белән икәү чүпләдек...

Безнең песи баласына да урман бете кадалган булып чыкты. Исән иде! Ишегалдыннан беркая чыгып йөрмәгән йодрык кадәрле бу мескен җан иясенә ул каян килгән?! Менә монысы чын табышмак иде. Чабып алып кайткан печәннән эләккәндер дип нәтиҗә ясадык. Шул печәнне кочаклап күтәреп, малларга кертеп бирдем бит дип, миңа вәсвәсәләнергә җитә калды: ничә көннәр үземә, табиблар кушканча, «ревизия ясап» тордым. Андый корт-бөҗәкләр белән бала чактан дуслыгым шул кадәрле генә.

Без түбән сыйныфларда укыганда, әле колорадо кортлары чыккан гына вакыт, колхоз акча түләп, аны балалардан, төрле эштә йөрүче хатын-кызлардан җыйдырта иде. Мин бер көн барып калдым. Башкалар яланкул җыйганда, пирчәткә киеп, анда да бәрәңге яфрагы белән генә җыйсам да, төн буе «монда корт, анда корт» дип кычкырып, өйдәгеләргә йокы бирмәгән булганмын. Шуннан соң әни мине колорадо коңгызы җыярга башка җибәрмәде.

Бу юлы да шактый изаландым (ни дисәң дә, алтыдагы – алтмышка!). Эш йокы аралаш саташуга барып җитмәсә дә, саклык чараларын хәйран күрдем әле, кайткан печәннәрне дә малларга сәнәк белән генә салдым...

Ә песи баласына берни булмады. «Бетле» килеш ничек уйнаса, шулай уйнавын дәвам итте. Ияк астында шактый зур гына «тишек» калса да (без бит ул урынны интернет кушканча, спиртлы мамык белән эшкәрттек), җәрәхәте берәр атнадан төзәлде.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең мәгълүмат технологияләре бүлеге башлыгы **Самойлов** Антон Витальевичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционерлык җәмгыяте генераль директорының коммерция буенча беренче урынбасары **Зуев** Дмитрий Владимировичка; «Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционерлык җәмгыяте 1 номерлы ашханәсе шеф-повары **Хәлиуллина** Әнисә Илдус кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Горький тимер юлларының техник сәясәт хезмәте технология бүлеге әйдәүче технологы **Айдарова** Надежда Михайловнага; «Түбән Каманың 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционерлык җәмгыяте автомобиль йөртүчесе **Петров** Иван Ивановичка, «Түбән Каманың 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционерлык җәмгыяте автомобиль йөртүчесе **Чернышов** Василий Ивановичка; «БИГЕШ» АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыятенең махсус транспорт һәм аэродром комплексы хезмәте башлыгы **Ульянов** Павел Георгиевичка; «КАМАтранссервис» транспорт-экспедиция фирмасы» акционерлык җәмгыятенең 2 номерлы автоколоннасы автомобиль йөртүчесе **Хәертдинов** Мөнәвир Өлфәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Фундаменталь медицина һәм биология институтының биоэкология, гигиена һәм җәмәгать сәламәтлеге кафедрасы мөдире **Рәхимов** Илгизәр Ильяс улына; «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең гомуми химия һәм экология кафедрасы мөдире **Тунакова** Юлия Алексеевнага **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЛЬБЕРТ ХУҖИН:

«БЕЗНЕҢ ӨСТӘЛ ТҮГӘРӘК»

Республиканың көнчыгыш өлешендә, ямьле Ык елгасы буена урнашкан Мөслим соңгы елларда тагын да матурланды, төзекләндерелде. Әмма камиллекнең чиге юк. Бүген дә биредә зур максатлар, бурычлар белән яшиләр. Район башлыгы Альберт ХУҖИН белән авыл хуҗалыгы, яшьләр һәм районның мөмкинлекләре турында сөйләштек.

:: Альберт Робертович, Мөслим – авыл хуҗалыгына йөз тотып эшләүче район. Ә бүген игенчеләрнең кызу урак өсте. Алда зур бурыч тора. Мөслимлеләр урып-җыюга нинди кәеф белән кереште?

– Кәефебез бик яхшы, чөнки быел җирдә эшләүчеләр өчен һава торышы уңай килде, басу-кырлар матур. Беренче урып-җыю күрсәткечләре дә яхшы, шуңа күрә мул уңыш җыеп алырбыз дип ышанам. Әлегә басуларга Исламов И.З. крестьян-фермер хуҗалыгы, «Туган як – Родные края», «Намус» («Агросила»), «Август-Мөслим» агрофирмалары һәм берничә вак фермер чыкты. Урып-җыю эшләренә аграрийлар тулы әзерлек белән килде. Кырларда 80 берәмлек техника, шул исәптән 34 комбайн хезмәт куя. Уңыш өчен көрәш көннән-көн көчәя бара, дип сөенеп йөрим. Бездә дүрт зур агрофирма эшли: «Август-Мөслим», «Намус» («Агросила»), «Агромастер» һәм «Туган як» («Чаллы икмәге»). Дүрт зур агрофирма булгач, сәламәт көндәшлек бар. Бер генә инвесторга бәйлелек юк. Аларның һәркайсы үзенчәлекле.

:: Яңа инвестор «Август» компаниясе эшеннән сез канәгатьме?

– Әлбәттә. Беренчедән, алар югары хезмәт хакы түли, заманча техникалар белән эшли. «Август» агрофирмасы, килү белән, бөтен иске тракторларны җибәрде дә техника өчен 4 млрд сумга якын инвестиция кертте, роботлаштырылган ферма төзеде. Безгә хәзер Актаныштан килеп эшлиләр. Районда яшьләр кала башлады. Икенчедән, алар күп салым түли. Димәк, районга файда дигән сүз. Моннан тыш, гектарына 200 сумнан төрле социаль программаларны тормышка ашыруда ярдәм күрсәтәләр. Безнең районга 6,5 млн сум туры килә. Сабан туена, ветераннарга, өлкәннәргә, медицина хезмәткәрләренә бүләкләр тараталар. Аның өстенә районлагы оешмаларга ярдәм итәләр. Күрсәткечләре дә яхшы. Бер сыердан тәүлегенә 30 литрга якын сөт савып алалар. Шуңа күрә район күрсәткечләре республика күләмендә дә югары. Алар бүген 32 мең гектар мәйданда эшли. Безнең районда язылмаган бер килешү бар: бер аграрий да бер-берсенең җирен тартып алмый. Бу – әлбәттә, мин генә урнаштырган тәртип түгел, электән килгән гадәт. Мин исә аны дәвам иттерергә тырышам. «Август» агрофирмасы килгәч, фермерлар да эшкә карашларын үзгәртте. Ул бездә «игенчелек культурасы»н арттырды. Башкалар да бик матур күрсәткечләр бирә. Авыр ел булуга карамастан, язын 250 млн сумлык техника алдык. Район буенча техника паркы яңарды. Пай җирләре өчен түләүләр белән дә проблема юк. «Агромастер» агрофирмасының республика буенча иң күп түләүче булуы ачыкланды. Кыскасы, районда эре агрофирмаларга да, уртачаларына да, кече фермерларга да урын җитәрлек. Иң мөһиме – бер-берсе белән сүзгә килү юк. Моннан тыш, кошчылык белән ныклап шөгыльләнәбез, тавыклар һәм казлар үстерәбез. Өч айлык кошларны ерак төбәкләрдән кадәр килеп алалар. Бездә элеккеге ферма биналарының берсе дә буш түгел. Барысында да фермерлар чеби үстерә. Кошчылыкта гына да 300дән артык кеше хезмәт куя.

Гомумән, авыл хуҗалыгы буенча үз юллары табылган һәм алар шуннан баралар. Безнең бурыч – белгәнне күрсәтү, киңәшләшү, тәҗрибә уртаклашу. Кыскасы, Мөслимдә җир кешесенә хөрмәт зурдан, чөнки без – аграр район. Бездә башкача була да алмый.

:: Сез берничә тапкыр яшьләр темасын кузгаттыгыз. Авылдан китү процессы тукталдымы, әллә ул дәвам итәме?

– Авылга кайтучылар бар. Яшьләр буенча шуны әйтәсем килә. Күп районнарда эшләп караган кеше буларак, Мөслимдә яшьләрнең «Без кемнәр?» дигән сорауга: «Без – мөслимлеләр!» – дип горурланып җавап бирүләрен ишеткәч, сокланган идем. Быел язын бөтен мәктәпләрдәге югары сыйныф укучылары белән күрешеп чыктым. Хәтта бер мәктәптә гитарада да уйнаттылар үземне. Майда Казанда якташлар очрашуы уздырдык. Анда эшмәкәрләрне, якташларны чакырдык. Ягъни ул Мөслим аксакалларының яшьләр белән очрашуы килеп чыкты. Мөслимгә кайткан очракта, нинди эшләр барлыгын, нинди хезмәт хаклары түләнүен сөйләдек. «Кайтырга уйламаган очракта да, якташларыбызга ярдәм итәбез, сез барыбер безнекеләр» дигән төп фикерне җиткердек. Яшьләр белән һәрдаим аралашып торабыз. Бильярд өстәле, музыка уен кораллары алдык, алдынгы укучыларны котладык. Районның башкарма комитеты егетләре белән яшьләрнең җыелма командасына каршы волейбол уйныйбыз. Яшьләр белән аралашу кирәк. Болар барысы да безнең араны якынайта. Алар өчен чит кеше түгел, ә үз кеше буласым килә. Яшьләр белән эшләүнең юлын бары тик шулай күрәм.

:: Эшчәнлегегезнең төп принципларыннан берсенең халык белән аралашып эшләү икәнен аңладык. Тагын нindiләргә таянып эшлисез?

– Әйе, яшьләр белән генә түгел, халык, фермерлар белән дә аралашып эшлибез. Икенчедән, районга килгәч, командама: «Мин сезгә боерык биреп эшләтүче кеше түгел, киңәшләшеп, һәр мәсьәләне уртага салып эшлик», – дидем. Без – бер йодрык, бер команда. Һәркем үз фикерен әйтеп эшләгәндә, нәтиҗә дә яхшырак булачак. Безнең өстәл дүртпочмаклы түгел, ә түгәрәк.

:: Районыгызда Сәламәтлек бишьеллыгы программасы тормышка ашырылып килә. Аның юнәлешләре белән дә таныштырсагыз иде. Сез әлеге программадан нинди нәтиҗә көтәсез?

– Кызганыч, районда демография күрсәткечләре начар иде. Мартта без үлүчеләр саны буенча кызыл зонадан чыктык. Ә Сәламәтлек бишьеллыгы ул – комплекслы программа. Аның кысасында, бердән, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалыйбыз, спортка игътибар бирәбез (киемнәр, кирәк-яраклар алдык), чаралар оештырабыз. Икенчесе – медицина. Бөтен ФАПларны йөреп чыктык, кирәкле җиһазлар алдык, «Агромастер» компаниясе хастаханәдә рентген аппаратының бик кыйммәтле чыбыкларын алыштырды. Шушы эшләр белән без халыкның сәламәтлеген кайгыртырга, аңа тагын да зуррак игътибар бирергә уйлыйбыз.

:: Үзегез өчен Мөслимнең үсеш ноктасы кайда дип билгелисез?

– Беренчесе – әлбәттә, авыл хуҗалыгы. Миңа калса, без әле бу тармактагы мөмкинлекләрнең 60 процентын гына файдаланабыз. Үсәргә мөмкинлекләребез бар әле. Мәсәлән, буаларыбыз күп булса да, балыкчылык белән шөгыльләнүчеләребез юк. Икенчедән, туризмны булдыру, үстерү юнәлешен җәелдерү буенча эшлибез. Өченчедән, эшмәкәрләр алдына интернет аша сатуны арттыру бурычын куйдык. Бездә моның буенча рәхәтләнеп эшләр өчен мөмкинлекләр бар. Төзелеш өлкәсен дә үстерергә кирәк дип саныйм.

Соңгы елларда Мөслим бик матурланды, төзекләндерелде – бу юнәлешне тагын да үстерү, камилләштерү эшләре алып барабыз. Мәсәлән, районда су белән тәэмин итүдә берникадәр кыенлыклар бар иде. Быел ике скважина казыттык, үзара салым программасы ярдәмендә берничә урамга су кертү буенча эшлибез. Шулай ук Мөслимдә асфальт түшәләсе урамнар да байтак – бу юнәлештә дә боз кузгалды, эшләребез башланып китте.

Мөслим – рәхәт итеп яшәр өчен бик матур җир. Үзем дә, гаиләм дә монда тынычлык табабыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«Татар-информ»

Алырга да, өйрәнергә дә була

Казанда «Тормыш стиле – мәдәни код» II Халык иҗаты һәм гамәли-декоратив сәнгать этно-fashion фестивале башланды.

Россиянең төрле төбәкләреннән 300гә якын халык һөнәрчелеге оешмалары, гамәли-декоратив сәнгать осталары, һөнәрчеләр һәм рәссамнар, дизайнерлар, модельерлар, иҗат берләшмәләре Казанга җыелды. Заманча мәдәният һәм иҗат фестивале БДБ, Европа һәм Азия илләреннән 100дән артык оста һәм һөнәрчене җыйган этномаркет ачылышыннан башланды. Кызыклы остаханәләр белән үрелеп барган «Тормыш стиле – мәдәни код» этномаркеты 2 августтан 7 августка кадәр Кабан күле яр буенда эшләячәк. Биредә традицион халык һәм сәнгать һөнәрчелеге эшләнмәләре, заманча авторлык эшләре дә тәкъдим ителгән.

Гомумән, фестиваль осталык дәресләренә, фикер алышуларга, ярминкәләргә, үзенчәлекле күргәзмәләргә бай булачак. Биредә теләгән һәр кеше халык сәнгате һәм мода белән якыннанрак таныша ала. Әлеге фестиваль – төрле милләтләрнең иҗади берләшү мәйданчыгы да. Фестиваль кысасында «Хәзинә» милли галереясында «Мирас һәм традицияләр» дип исемләнгән сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгать күргәзмәсе эшләячәк.

Этномаркетта тәүге тапкыр Ингушетия, Чувашия, Удмуртия, Саха (Якутия), Чиләбе, Липецк, Иваново һәм Пенза өлкәләре вәкилләре катнаша. Фестиваль Россиядә милләтара татулыкны ныгытуны, Россия, Европа һәм Азиядән килгән осталар арасындагы хезмәттәшлекне үстерүне күз алдында тота.

Чараның ачылу тантанасында Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова исеменнән Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге җитәкчесе Алсу Мифтахова сәламләде һәм Россиянең сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Гөлназ Кадыйрованың сәламләү хатын укыды.

«Фестиваль Россия төбәкләре арасында мәдәни киңлекне һәм мәдәни элемтәләрне ныгытуда зур роль уйный. Ул катнашучыларга тупланган тәҗрибәләрен алмашырга һәм халык сәнгать һөнәрчелеге өлкәсендәге актуаль мәсьәләләрне чишәргә ярдәм итәр дип ышанам», – диелә хатта.

Халык сәнгать кәсепләре оешмалары, һөнәрчеләр һәм рәссамнар ассоциациясенең идарә рәисе урынбасары Алексей Комаров әйтүенчә, фестиваль күпкырлы булуы белән үзенчәлекле:

– Без монда халык сәнгать һөнәрләренең үзенчәлекле эшләнмәләрен генә күрсәтеп калмыйбыз, теләге булган һәр кеше үзенең осталыгын да сынап карый алачак.

Табигый ташлардан төрле бизәнү әйберләре ясаучы Эльмира Габдрахманова этномаркетта катнашырга Санкт-Петербургтан килгән.

– Мондый кәсеп белән инде 7 елдан артык шөгыльләнәм. Элек кибет тота идем, анда табигый ташлар, төрле муенсалар, беләзекләр саттым. Аннары аларны үзем ясый башладым. Мин үзем – Дагыстаннан. Анда күбрәк көмеш, алтын бизәнү әйберләре популяр. Ә мин заманча стильдә эшлим. Эшләнмәләрем арасында көнчыгыш бизәнү әйберләре дә, заманча геометрик элементлылары да, этник бизәнү әйберләре дә бар. Мин – иҗади шәхес, гел бер үк нәрсә белән генә шөгыльләнә алмыйм. Яңа идеяләр туып тора һәм мин аларны шундук тормышка ашырам. Беренче чиратта моны кешеләр өчен, аларга файдалы булсын дип эшлим. Бу бик мөһим, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ?

Яшәеш

Татарстанда 6013 коммерциясез оешма эшли. Аларның һәркайсының үз юнәлеше бар. Араларында авыруларны, ялгыз аналарны, әтиләрне, күпбалалы гаиләләрне кайгыртучылар да бар. Нинди генә эш башкарсалар да, аларның максаты бер: башкаларга ярдәм итү. Татарстанның Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева да соңгы очрашуда коммерциясез оешмаларның халык белән дәүләт арасында күпер булып торуын әйткән иде. Бу чынлап та шулаймы? Коммерциясез оешмалар ничек эшли? Аларның үзләренә ярдәм кирәкме? Без берничә оешма җитәкчесе белән сөйләштек.

«НеЗаМи»

Әлеге хәйрия фонды җитәкчесе Флера Җәләлиева күзләре күрми торган сабыйларга музыка белән шөгыльләнергә мөмкинлек тудыра.

– 2013 елда Казанда «НеЗаМи» ансамблен оештырык. Безнең һәр эшебезне музыкант һәм педагог, ансамбль җитәкчесе Дмитрий Бикчәнтәев хуплап торды. Өч күрмәүче баланың фамилияләренең алдагы ике хәрефен алып, ансамбль исемен уйлап таптык. Ул ансамбльдә ничәмә-ничә бала укып, күпме музыка коралында уйнарга өйрәнде. Без, әлеге ансамбльгә йөрүче балаларның әниләре, шушы исемдәге хәйрия фондын да ачарга булдык, – ди Флера Җәләлиева.

Әмма фонд ачу җиңел генә бирелми. Музыкага тартылучы сабыйлар күп, ә мөмкинлек чамалы. Флера Җәләлиева үзе дә яшерми, аларның фонды бары тик грантлар хисабына яши. Ә аны оту җиңел түгел. Лотерея кебек – йә отасың, йә юк.

– Кайчакта акчабыз коммуналь хезмәтләр өчен түләргә дә җитми. Ә эшне дәвам итәргә кирәк. Шуңа да без гел даими ярдәмгә мохтаҗ, – ди Флера Җәләлиева. – Әлегә бер бинада шөгыльләнәбез. Әмма йортта яшәүчеләр музыка тавышына риза түгел. Аларны да аңларга була. Безнең ишеккә еш шакыйлар, хатлар калдыралар. Әмма без нишли алабыз? Бу бинаны безгә шәһәр хакимияте бирде. Ул Авиатөзелеш районында урнашкан. Үзәктән ерак булгач, кайбер балаларны шөгыльләнергә алып килә алмыйлар. Аерым бер бинага урнаша алсак, бар да яхшырыр иде.

Узган ел «НеЗаМи» хәйрия фонды Президент грантын ота алмаган. Әмма алар «Россиянең иң яхшы 100 проекты» исеменә лаек булган. Шөкер, быелга финанс ягыннан авыр хәлдә калмаганнар. Президент Аппараты һәм бер сәнәгать оешмасы аларга матди ярдәм күрсәткән.

«Сила в детях» («Балаларда – көч»)

– Әлеге оешма 2014 елдан бирле эшләп килә. Безнең тагын бер оешмабыз да бар. Анысы «Фәрештәләргә шатлык өләшик» дип атала. Ул 2019 елда эшли башлады. Икесе дә сабыйларга ярдәм юнәлешендә эшли. Без физик мөмкинлеге чикләнгән сабыйлар үстерүче авыр хәлдә калган гаиләләргә ярдәм итәбез, – ди «Балаларда – көч» оешмасы җитәкчесе Адель Заһретдинов.

Аның сүзләренчә, алар авыру балаларга тернәкләндерү курслары үткәрәләр. Махсус үзәкләрдә сабыйларның сәламәтлеген ныгыталар. Казан, Түбән Кама, Чистай, Лениногорск шәһәрләрендә аларның биш үзәге авыру балаларга хезмәт күрсәтә.

– Түбән Камадан кала, башка шәһәрләрдә үзәкләргә биналарны бушлай бирделәр. Әлеге биналарда грант акчасына төзекләндерү үткәрелде. Шулай ук дәүләт ярдәме белән без үзебезгә кирәкле махсус җиһазлар алабыз. Бездә 130 кеше эшли. Алар – медицина, психология, педагогика белгечләре. Үзәкләр туганнан алып 18 яшькәчә булган балаларга ярдәм күрсәтә, – ди җитәкче.

Адель Заһретдинов әйтүенчә, ел саен 3 меңгә якын бала тернәкләндерү уза. Дәваланырга килүчеләр арасында ДЦП, нерв авырулы сабыйлар, аутизм, Даун синдромы, сөйләм үсеше туктап калган балалар бар.

– Соңгы елларда коммерциясез булган оешмаларга дәүләт тарафыннан караш үзгәрде. Без һәрдаим аларның җылысын, ярдәмен тоеп яшибез. Төрле грантлар отып, бәйгеләрдә катнашып, матди хәлебезне яхшыртабыз, – ди оешма җитәкчесе.

«ЗАКАЛ»

Алабугада эшләп килүче «Закал» коммерциясез оешмасы да узган ел Татарстан Президентының премиясен алган. Әлеге оешма физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрнең тормышын яхшырту өчен барысын да эшли. Оешма җитәкчесе Рөстәм Латыйпов сүзләренчә, 15 ел эшләү дәвамында алар бик күп кешеләргә ярдәм кулы сузган.

– Кайчакта авырулар үзләренең хокукларын да белми. Әнә шул чакта юл күрсәтәбез. Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр эшкә урнашу тәртибен, «Уңайлы мохит» турында, үзләренә кагылышлы юридик сорауларга бездә җавап табалар. Без аларның һәр үтенечен уңай хәл итәргә тырышабыз, – ди Рөстәм Латыйпов. – Соңгы вакытта безнең оешмада «Добрый прокат» дигән социаль проект эшли башлады. Без аларга шушы проект кысасында йөзләгән кешегә бушлай техник тернәкләндерү чаралары биреп торабыз.

Алар киләчәктә башкаларга ярдәм итүләрен туктатмаячаклар. Киресенчә, төрле грантлар отып, үз эшләрен җәелдермәкчеләр. Рөстәм Латыйпов матди ярдәм күрсәтүләре өчен республика җитәкчелегенә рәхмәтен җиткерә.

– Төрле бәйгеләрдә оту – безгә канат куя. Бу бит әле – акча бирү генә түгел, синең эшеңне бәяләү дә, – ди Рөстәм Латыйпов. – Ә инде башкаларны сөендерү көч өсти. Күңелдә рәхәтлек хисе барлыкка килә. Башкаларның рәхмәтен ишетеп яшәүгә ни җитә?

vk.com

«НеЗаМи» хәйрия фонды күрмәүче балаларга мөмкинлекләр тудыра.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Исәнмесез! Салам лийже!

МАРИ

Кукмара районының Починок-Кучук авылында бу сүзне өч телдә дә бертигез әйтәләр. Мари, татар, урыс, удмурт һәм хәтта украин, чуаш, вьетнам, казах, азәрбайҗан халкы вәкилләре дә дус-тату яшәп ята монда. Авыл халкының яртысын тәшкил итүче марилар үз телләрен, йолаларын, традицияләрен, җыр һәм биюләрен ничек саклый? Нәрсә өчен борчылалар? Шушы сорауларга җавап эзләп, Починок-Кучук авылына юл тоттык. Анда безне «Салам лийже!» дип, үзләренә генә хас кунакчыллык белән каршы алдылар.

ҖЫРЛЫ АВЫЛ

Кукмара

Марилар яши торган Починок-Кучук авылына печән өстенең иң кызган чорында килдек. Тракторлар чабыша, халык – бакчада, басу-кырларда. Элек-электән кеше җиргә тартылган монда, шуның белән көн күргән. Күпләп терлек, умарта тоткан авыл халкы. Хәзер дә умартачылар шактый, шулай ук һәр йортта кәҗә булса да асрыйлар.

Починок-Кучукка XVI гасырның икенче яртысында ук нигез салынган. Бу җирләргә Кучук атлы кеше килеп төпләнгән дип исәпләнә. Починок исә башлангыч дип тәрҗемә ителә. Хәзерге вакытта Починок-Кучук җирлегенә сигез авыл карый, 400ләп хуҗалык бар. Шуларда барлыгы 1030 кеше теркәлгән, ә авылда яшәүчеләрнең саны – 840. Авыл җирлеге башлыгы Риналь Гыйниятов сүзләренә караганда, монда яшәүче марилар һәм татарларның саны бертигез, 47шәр процент. Калганнары – урыс, удмурт, украиннар. Бер чуаш, казах, вьетнам, азәрбайҗан да шушы җирлектә гомер кичерә. «Авыл өлкәннәр кулына калып бара. Кызганыч, яшьләр күбрәк каланы сайлый. Ләкин барысы да түгел. Үзебездә калучылар да бар, өметне өзмибез», – ди башлык.

Мозафаровлар йорты

Авылның мәктәбе, мәдәният йорты урнашкан үзәк урамнан Мозафаровлар яшәгән йортка таба атлыйбыз. Мари теле укытучысы, юлдашыбыз Ирина Вячеславовна авыл белән таныштыра. Элек марилар һәм татарлар төрле урамнарда яшәгән икән. Хәзер инде мондый бүленеш юк, катнаш никахлар да шактый, ди Ирина ханым.

42 ел бергә гомер кичерүче Маргарита Захаровна белән Сергей Николаевич – авылның хөрмәтле кешеләре. Икесе дә – укытучылар. Маргарита Захаровна лаеклы ялда булса, Сергей Николаевич әле дә балаларга физика һәм информатика фәннәреннән белем бирә.

Гаилә башлыгы – күрше Мамадыш районыннан. «Мин үзем шушында тудым, шушында үстем. Сергейның безнең яндагы Нырты авылында укытучы булып эшләгән мәле. Ә мин шунда кичке уенга барган идем. Янымнан узып китүе булды, шунда ук, менә бу минем булачак ирем, дип уйлап куйдым», – дип искә ала Маргарита ханым.

Язмыш үзе очраштырган инде аларны. Икесе дә укытучы – бер-берсен яхшы аңлыйлар. Алай гына да түгел, икәүләп авыл тарихын, мари халкының гореф-гадәт һәм традицияләрен өйрәнергә һәм укучыларына шуны өйрәтергә алына алар. «Барын да күреп үссәк тә, истә калмаган шул. Балаларга өйрәтер алдыннан үзебезгә өйрәнергә туры килде. Күпме байлыкны кулдан ычкындырганыбызны шунда гына аңладым... Авылдан-авылга йөреп, җырлар, әкиятләр, гореф-гадәтләрне барларга, тупларга туры килде. Хәзер инде аларны белгән кеше бик сирәк», – ди башлангыч сыйныфларны укыткан Маргарита Захаровна. Яшь буынга милли традицияләрне «сеңдереп» калырга теләсәң, тиешле мохит тудырырга кирәк дигән фикердә ул.

Берникадәр вакыттан соң Мозафаровлар тырышлыгы белән мәктәптә туган якны өйрәнү музее да ачыла. Экспонатларны шактый озак тупларга, бик күп көч куярга туры килә аларга. «Өйдән-өйгә йөрдек, кайберәүләрдән ялынып сорарга туры килде. Әле дә тарих белән «янып» йөргән чагыбыз. Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннарыбызны барлыйбыз. Сугышка башка җирдән киткәч, безнең авылныкы булып саналмаганнар. Интернетны ачып карасак, солдатларыбыз бик күп булган икән. Инде 1000ләп яңа исем теркәдек», – ди Маргарита ханым.

Безнең Маргарита!

Авылда аны «безнең Маргарита» дип йөртәләр. Сергей Николаевич белән ничәмә-ничә бәйрәм уздырган алар. Әле дә милли бәйрәмнәргә сценарийлар яза Маргарита ханым. «Киңәш, ярдәм сорап килгән кешене кире борганыбыз юк. Сөенәбез генә! Бездә Сурем – Изге аланда корбан бәйрәме бар. Аның рәтен өйрәнеп, дәфтәргә язып куйдык. Хәзер менә бездән сорыйлар», – ди Сергей Николаевич.

Мари гына түгел, татар халкы бәйрәмнәрендә дә актив катнашалар. «Сабантуйны күтәп алабыз. Гает икән, таба исе чыгарып, коймак пешерәбез. Азан әйткәндә яки бәйрәмнәрдә эшләми торабыз. Киявебез – татар милләтеннән. Шуңа күрә йортта татар, урыс, мари сүзләре бертигез яңгырый. Ә башкача була аламыни? Күрше хакы бит ул!» – ди Маргарита Захаровна.

Тел, милләт, традицияләр яши алырмы? Әлеге гаиләне дә борчый бу сорау. «Бик күп уйланам бу турыда. Кайчак хәзерге буын белән безнең арада упкын бар сыман тоела. Ләкин өметне өзәргә ярамый. Яшьләрне көчләп өйрәтеп, менә моны эшлә, дип булмый. Аларны кызыксындырырга, кечкенәдән бәйрәмнәрдә катнаштырырга кирәк. Күреп кенә түгел, «татып» та үссеннәр», – ди Маргарита Захаровна.

Бии-бии кавышалар

Шуннан соң без авылдагы мәдәният йортына юл тоттык. Монда безне куас, коймак, якты йөз һәм тәмле тел белән каршы алдылар. Аннан авылны дөнья күләмендә танытган «Кна вел» ансамбле белән таныштырдылар.

«Кна вел» мари халык ансамбле 1985 елда ук оеша. Шул вакыттан бирле, җырга-моңга төреп, 200ләп кешене тәрбияли ул. Еллар узса да, максатлары бер – бәһасез рухи мирасны буыннан-буынга тапшыру.

Хәзерге вакытта ансамбльгә 40лап кеше йөри. Әле генә мәктәп бусагасын атлап кергән балалардан алып 80 яшьлек әби-бабайларга кадәр җырлый, бии, халык уен коралларында уйный «Кна вел»да.

– Ансамбльне Моисей Ямбулатов белән бергә оештырдык. Аңа кадәр кайбер татар авылларында Кукмара районында марилар яшәвен белмәүчеләр бар иде хәтта. Ул вакыттан бирле күпме сулар аккан инде, ничә буын алышынган, – ди ансамбльнең җитәкчесе Леонид Искаков. Ул шулай ук бу җирлекнең карты (мариларның дин әһеле – каһине шулай атала) булып тора.

1992 елда «Кна вел» халык ансамбле статусын ала. Эстония, Финляндия, Казахстан – кайда гына булмый алар. Мари Иле, Киров өлкәсе, Удмуртия, Татарстанны аркылыга-буйга йөреп чыгалар.

– Чит илләргә, төбәкләргә еш чакыралар безне. Эстониядә генә дә, ялгышмасам, өч мәртәбә булдык. Үзебездә уза торган бәйрәм-фестивальләрне дә калдырмыйбыз, – дип сөйләвен дәвам иттерде әңгәмәдәшебез.

Хәзер төп игътибарны яшь буынга бирәләр икән. «Еллар буе туплаган тәҗрибәне, гореф-гадәт һәм йолаларны, традицияләрне ике арада күпер салып кына саклап калып була», – ди Леонид Искаков.

– Без инде яшәрмибез, үзебезгә дәвамчылар әзерләргә кирәк. Бүген мәктәп укучыларының күпчелеге безнең ансамбльгә йөри. Марилар гына түгел, татар милләтеннән булган яшьләр дә бар араларында. Кызыксынып киләләр, дөбер-шатыр бииләр. Без ата-бабаларыбыздан өйрәнгән кебек, алар бездән күреп, белеп үсәргә тиеш. Кызганыч, авылда яшьләр калмый диярлек, эш эзләп, читкә китәләр. Бар өмет – мәктәпкә, – ди ул.

Телне саклауда да өлешләре зурдан аларның. Әңгәмәдәшебез әйтүенчә, балалар белән дә, үзара да мари телендә сөйләшәләр.

– Башка төбәкләрдә яшәүче мариларның үзара урысча аралашуына исем-акылым китә минем. Балалар гына түгел, өлкәннәр дә сөйләшми бит үз телләрендә! Мари иленә барып, бер кәлимә мари сүзе ишетми кайткан чаклар булды. Әле ярый мәктәбебездә мари теле дәресләре укытыла, гаиләләрдә аралашалар, – ди Леонид Искаков.

«Кна вел» эшләү дәверендә 13ләп мари биюен сәхнәгә чыгарган. Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче мариларның үзенчәлекле җыр-биюләрен өйрәнеп һәм яшьләргә өйрәтеп, бүген дә күз карасыдай саклыйлар аларны.

– Кукмара мариларының горурлыгы – «сигезле» биюе. Аны дөрес итеп бездә генә бии беләләр. Әби-бабаларыбыз шул биюдә үзләренә пар тапкан, кавышканнар. Парлы бию бит ул, егет кеше күзе төшкән кыз каршына басып тыпырдый. Шуннан кызның җавабын көтә. Ул да егетне ошатса, бергә бииләр. Хәзер инде халык биюләре сәхнәгә менде. Алай да, безнең ансамбльдә табышып, кавышкан парлар байтак, – дип сөйли әңгәмәдәшебез. – «Кна вел»да бии-бии кавышып, бүген инде әби һәм бабай булган парлар да бар. Иң сөендергәне – балаларын да алып киләләр, – ди ансамбль җитәкчесе.

Тәмле булсын!

Коман мелна (катлы белен)

Мозафаровлар безне коман мелна дигән милли ризыклары белән каршы алды. Маргарита Захаровна әйтүенчә, аны иң кадерле кунаклар өчен генә әзерлиләр. Ә рецепты болайрак. Камыр өчен 1–1,5 стакан җылы су, бер чеметем тоз, 1,5 аш кашыгы үсемлек мае һәм каймак, бер чеметем разрыхлитель һәм он кирәк булачак. Камыры кыстыбыйныкына охшаган. Камырны җәеп, коры табада пешереп алырга кирәк.

Эчлек өчен: 1 кило эремчек, 4 йомырка, тәменчә шикәр комы, бер чеметем тоз, бер уч тирәсе манный ярмасы, 1,5 аш кашыгы үсемлек мае һәм каймак, бераз сөт кирәк. Шушы эчлекне әзер камыр өстенә сылыйбыз да, йөзе килгәнче, мичкә яки духовкага озатабыз. Әзер беленнәргә эретелгән атланмай сөртәбез.

Сүзлек

Исәнмесез! – **Салàм лӥйже!**	Хәлләрегез ничек? – **Кузè пашадà кая?**
Сәлам! – **Салам!**	Туган тел – **Шòчмо йылме.**
Хәерле иртә! – **Пòро эр!**	Әни – **Авай.**
Хәерле көн! – **Пòро кèче!**	Әти – **Ачай.**
Хәерле кич! – **Пòро кас!**	Мин сине яратам! – **Мый тый́ым йöратèм!**
Сау бул! – **Чевèрын!**	
Рәхмәт! – **Тàу!**	

Бар да телдән башлана

Кая гына барсак та, бу сүзләрне еш ишетәбез. Починок-Кучук авылы халкы да шулай ди. Шуңа да өйдә дә, урамда да, балалары белән дә, гомумән, кая гына барсалар да, үз телләрендә сөйләшергә тырышалар.

Билгеле, бу мәсьәләдә мәктәп тә зур роль уйный. Починок-Кучук урта мәктәбе – райондагы мари теле укытыла торган бердәнбер белем йорты. 2021–2022 уку елын барлыгы 65 бала тәмамлаган. Шуларның яртысы – марилар, калган яртысы – татарлар.

– 2017 елдан 1–11 сыйныфларда мари теле дә, татар теле дә туган тел буларак укытыла башлады. Бүген балалар атнага өчәр сәгать үз телләрен өйрәнә, – ди мәктәп директоры Алмаз Фәйзрахманов.

Ләкин моның белән генә чикләнми алар. Телгә карата мәхәббәтне милли бәйрәмнәр, фестивальләр аша да тәрбиялиләр. Мәктәптә мари һәм татар халкының төп бәйрәмнәрен уздыралар, барысын да укучылар үзләре әзерли. Узган уку елында төбәкара мари мәдәнияте фестивален дә башлап җибәргәннәр.

– Дәресләрне дә уен формасында уздырырга яратам. Укучылар үз телләрен теләп, кызыксынып өйрәнә, – ди мари теле укытучысы Ирина Родыгина.

Мәктәп директоры сүзләренә караганда, туган телне белүдә әти-әниләрнең өлеше зур. Балаларына үз туган телен өйрәтмәүче, мәктәптә дә аны сайламаучы әти-әниләргә шаккаталар монда, андый хәлләр белән бер дә очрашканнары юк.

Ләкин тел өйрәнү теләк белән генә чикләнми шул. Тиешле әсбаплары да кирәк.

– Төп проблемабыз һәм иң авырткан урыныбыз – яңа дәреслекләр булмау. Мари теле дәреслекләре Мари Иле Республикасында басыла. Ел саен заказ бирәбез – нәтиҗәсез. Иң яңа дигән дәреслекләребез 2015 елгы иде. Узган ел көч-хәл белән бишәр данә 2018 елгы дәреслекләр табып алып кайттык. Ләкин бу бик аз, – ди Алмаз Фәйзрахманов.

Дәреслекләр генә түгел, мари теле һәм мәдәниятенә багышланган интернет чыганаклар да бик аз. Ирина ханым шулай ди.

– Әйтик, урыс теле укытучысы теләсә кайсы китап кибетенә кереп, үзенә кирәкле дәреслек, методик кулланма таба ала. Туган тел укытучылары, нинди генә телне алсаң да, мондый мөмкинлеккә ия түгел. Интернетта да мәгълүмат табу бик кыен. Миңа калса, хәзерге заманда мондый проблема, гомумән, булырга тиеш түгел, – ди ул. – Заман укытучыларын берләштерә торган тагын бер проблема бар. Алар үзләренә ышанмый, хәтта туган тел дәресләренең әһәмиятен дә аңлап бетерми. Шуңа да укучыларга үз фәнен тиешле дәрәҗәдә өйрәтә алмый. Укытучының үзен һәм укыта торган фәнен нинди позициягә куюыннан да күп нәрсә үзгәрә.

Туган телне ничек сакларга? Иң беренче чиратта, үз телеңдә сөйләшергә кирәк.

– Ни дәрәҗәдә белүең мөһим түгел – сөйләш кенә. Иң гади һәм әһәмиятле кагыйдәсе шул аның. Сөйләшүдән туктыйбыз икән, мәктәпләрдә укытылуыннан бернинди файда булмаячак. Туган теле, мәдәнияты һәм фольклоры сакланган милләт кенә милләт була ала, – ди бу хакта мари теле укытучысы.

Сәхифәне Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде.
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6688 данә
Гомуми тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 311

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+